**Үзәкләшкән дини оешма –**
**Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте**
**Балтач мөхтәсибәтенең Балтач үзәк мәчете мәхәлләсе**
**мөселманнарының урынлы дини оешмасы**
**Мәгърифәт мәркәзе**

# Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү программасы

**Балтач**
**2021**

**Үзәкләшкән дини оешма –**
**Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте**
**Балтач мөхтәсибәтенең Балтач үзәк мәчете мәхәлләсе**
**мөселманнарының урынлы дини оешмасы**
**Мәгърифәт мәркәзе**

**“Раслыйм”**
Балтач районы мөхтәсибе

_________ Җәлил хәзрәт Фазлыев

Төзүчеләр:
Бикбаев Рамил Басыйр улы – Балтач үзәк мәчете имам-хатыйбы, мөгаллим
Халиуллина Айгөл Вәкил кызы – Мәгърифәт мәркәзе мөдире, мөгаллимә

Программа авторлары:
Зарипова Гүзәл Фәргать кызы, Сәмигуллина Гөлназ Мөнир кызы, Хөснетдинова Фәйрүзә Рәхимҗан кызы – Балтач үзәк мәчете каршында Мәгърифәт мәркәзе мөгаллимәләре

**Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү программасы. - Балтач: 2021. – 87 бит. Беренче басма.**

Әлеге хезмәт Балтач үзәк мәчетендә мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү тәҗрибәсен туплап төзелгән программа. Мәчет каршында кече яшьтәге балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирүдә кулланырга мөмкин.

## ЭЧТӘЛЕК

**1. Мәктәп яшендәге балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү программасы** 4
1.1. Аңлатма язуы 5
1.2. I мустәвә дәресләренең тематикасы 6
1.3. II мустәвә дәресләренең тематикасы 8
1.4. III мустәвә дәресләренең тематикасы 11
1.5. Әдәп-әхлак дәресләренең тематикасы (I-III мустәвә) 13
1.6. Кулланылган әдәбият 14
**2. Мәктәпкәчә яшьтәге (3-7 яшь, атна дәвамында йөрүче) балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү программасы** 17
2.1. Аңлатма язуы 18
2.2. Рухи хәзинә 22
2.3. Коръән әлифбасы 24
2.4. Гыйбадәт 25
2.5. Коръән 26
2.6. Әдәп-әхлак дәресләренең атналык планы 28
2.7. Кулланылган әдәбият 51
**3. Атнага бер көн йөрүче 3 - 7 яшьлек балалар өчен (шимбә көн) рухи-әхлакый тәрбия бирү программасы** 53
3.1. Көндәлек тәртип 54
3.2. Аңлатма язуы 55
3.3. Әдәп-әхлак 58
3.4. Гыйбадәт 59
3.5. Иман 60
3.6. Дәресләр эчтәлеге 61
3.7. Дога үрнәге 85
3.8. Кулланылган әдәбият 86

**Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү программасы**

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

1. Гомуми
   1.1 Әлеге хезмәт Балтач мөхтәсибәтенең намаз һәм Коръән бәйгеләре нигезләмәсенең укыту программасы.
   1.2 Программаның максаты: өч ел эчендә баланы Коръән укырга өйрәтү, намаз нигезләрен ныгыту, аннан тиләвәт һәм хифз (ятлау) дәресләре белән Коръәнне уку һәм ятлау.
   1.3 Укулар атнага ике тапкыр икешәр сәгать бара (пәнҗешәмбе һәм җомга 15.00-17.00 сәг).
   1.4 Әлеге программа мәктәп яшендә укучы (1-3 сыйныф) балалар өчен төзелә.
   1.5 Укучылар өч мустәвәгә (сыйныфка) бүленә.
   1.6 Балалар дәрескә кадәр тәмле чәй белән сыйлана.
   1.7 Балалар туры мәктәп укуыннан соң килгәнгә, өй эшләре бирелми. Дәресләр еш кабатлау юлы белән шөгыль вакытында ныгытыла.
2. Беренче мустәвә. Бурычлар:
   2.1 Балага гарәп хәрефләрен таныту һәм кушып укырга өйрәтү.
   2.2 Мөгаллим сәни дәреслеге буенча һәр хәреф һәм үткән биш хәрефне кабатлау ысулы белән алып барыла.
   2.3 Намаз дәресендә 2 рәкәгать намаз укырга өйрәтү.
3. Икенче мустәвә. Бурычлар:
   3.1 Гарәп хәрефләрен яңадан кабатлап, Мөгаллим сәнидәге гади тәҗвид кагыйдәләрен кулланып, Коръәнне укырга өйрәтү.
   3.2 Язу дәфтәрен (пропись) хәрефләр язу белән ныгыту.
   3.3 Намаз дәресендә 5 вакыт намаз укырга өйрәтү.
4. Өченче мустәвә. Бурычлар:
   4.1 Тулы тәҗвид кагыйдәләрен исемнәре белән өйрәтү.
   4.2 Тиләвәт. Коръәнне тәҗвид кагыйдәләре (Коръәннән табып күрсәтү) белән укырга өйрәтү.
   4.3 Хифз. Намаз догаларын ныгыту, сүрәләр ятлау.
   4.4 Төп иман нигезләрен өйрәтү.

Барлык мустәвәдә укучылар дәрестә дога һәм зекерләрне кабатлый. Укучылар белән берлектә көнгә бер намаз укыла (икенде яки ахшам). Балалар Аятел Көрси, азан һәм тәкаббәл догаларын кычкырып, имам артыннан кабатлыйлар. Намаз беткәч, түгәрәккә утырып имамнан нәсыйхәт алалар.

5. Укулар түбәндәге китаплар нигезендә үткәрелә:

1. Мөгаллим сәни.
2. Язу дәфтәре.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: “Хозур” – “Тынычлык” нәшрият йорты, 2017. – 608 б.

4. Тәҗвид. Коръән уку кагыйдәләре. Г.Харисова., Казан., 2007 ел.
5. Җәлил хәзрәт дәресләре. Казан, 2012 ел.
6. Ислам тәрбиясе. К.Вәлиуллин., Казан., 2012 ел.

## I МУСТӘВӘ
## КОРЪӘН ӘЛИФБАСЫ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Гарәп иленә сәяхәт. Гарәп теле турында кыскача мәгълүмат | 1 |
| 2 | Гарәп язуының үзенчәлекләре. Хәрәкәләр. Әлиф хәрефе белән танышу ا | 1 |
| 3 | Ра хәрефе белән танышу. Хәрәкәләрне бер-берсе белән кушып укырга өйрәнү. ر | 1 |
| 4 | Сәкен. Зә хәрефе белән танышу. ز | 1 |
| 5 | Мим хәрефе белән танышу. م | 1 |
| 6 | Тә хәрефе белән танышу. ت | 1 |
| 7 | Нүн хәрефе белән танышу. ن | 1 |
| 8 | Йәй хәрефе белән танышу. ى | 1 |
| 9 | Бә хәрефе белән танышу. ب | 1 |
| 10 | Кәф хәрефе белән танышу. ك | 1 |
| 11 | Ләм хәрефе белән танышу. ل | 1 |
| 12 | уау хәрефе белән танышу. و | 1 |
| 13 | Һә хәрефе белән танышу. ه | 1 |
| 14 | Фә хәрефе белән танышу. ف | 1 |
| 15 | Каф хәрефе белән танышу. ق | 1 |
| 16 | Шин хәрефе белән танышу. ش | 1 |
| 17 | Син хәрефе белән танышу. س | 1 |
| 18 | Сакау Сә хәрефе белән танышу. ث | 1 |
| 19 | Сад хәрефе белән танышу. ص | 1 |
| 20 | Та хәрефе белән танышу. ط | 1 |
| 21 | Җим хәрефе белән танышу. ج | 1 |
| 22 | Ха хәрефе белән танышу. خ | 1 |
| 23 | Хә хәрефе белән танышу. ح | 1 |
| 24 | Гайн хәрефе белән танышу. غ | 1 |
| 25 | Гәйн хәрефе белән танышу. ع | 1 |
| 26 | Дәл хәрефе белән танышу. د | 1 |
| 27 | Дад хәрефе белән танышу. ض | 1 |
| 28 | Зәл хәрефе белән танышу. ذ | 1 |
| 29 | За хәрефе белән танышу. ظ | 1 |
| 30 | Калькалә ب د ج ط ق | 1 |
| 31 | Озын сузыклар ( мәдд хәрефләре) ا و ى | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 32 | Икеләтеп укыла торган хәрефләр (тәшдид) | 1 |
| 33 | Тәнвин. Тәнвин белән тәшдиднең бергә килүе | 1 |
| 34 | Тә-марбута  ة | 1 |
| 35 | Һәмзә ء ,  кушылу (Васыл) | 1 |
| | Барлыгы | 35 |

## ГЫЙБАДӘТ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ

| **Дәрес** | **Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|---|
| 1 | Ислам дине турында мәгълүмат бирү. Гамәл кылу. | 1 |
| 2 | Галәмнәрнең Раббысы Аллаһ. | 1 |
| 3 | Исламда сәлам бирү. | 1 |
| 4 | Ислам диненең 5 баганасы. Аның әһәмияте | 2 |
| 5 | Намаз. Гомуми мәгълүмат. Намаз әдәбе. Намазның шартлары | 1 |
| 6 | “Тәһарәт” төшенчәсе. Фазыйләтләре. Тәһарәт алу тәртибе, әдәбе | 1 |
| 7 | Кыйбла. Азан | 1 |
| 8 | “Әгузү”, “Бисмилләһ” | 1 |
| 9 | “Әл-Фәтиха” сүрәсе. Өстенлеге | 2 |
| 10 | Мөселманнарның изге китабы - Коръән | 1 |
| 11 | Тәкбир. Сәнә | 1 |
| 12 | “Ихлас” сүрәсе | 2 |
| 13 | Мөхәммәт саләллаһу гәләйһи вәссәләм минем өчен үрнәк | 1 |
| 14 | “Кәүсәр” сүрәсе | 2 |
| 15 | Рөкугъ зекерләре | 1 |
| 16 | Сәҗдә зекерләре | 1 |
| 17 | Беренче пәйгамбәребез Адәм гәләйһиссәләм | 1 |
| 18 | Әттәхият | 3 |
| 19 | “Кәлимәтүн таиибәтүн” кәлимәсе | 1 |
| 20 | Салават | 3 |
| 21 | “Кирамун Кәтибин” фәрештәләре | 1 |
| 22 | Раббәнә | 1 |
| 23 | Сәлам догасы | 1 |
| 24 | Аятел Көрси | 3 |
| 25 | 2 рәкәгать намаз тапшыру. | 1 |
| | Барлыгы | 35 |

## II МУСТӘВӘ

## КОРЪӘН ӘЛИФБАСЫ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ

| Дәрес | ЭшчәнлекнеҢ тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Гарәп теле турында кыскача мәгълүмат. | 1 |
| 2 | Гарәп язуының үзенчәлекләре. Хәрәкәләр. Әлиф, ра,зә хәрефләрен кабатлау ا ر ز | 1 |
| 3 | Мим, тә хәрефләрен кабатлау م ت | 1 |
| 4 | Нүн, йә хәрефләрен кабатлау ى ن | 1 |
| 5 | Бә, кәф хәрефләрен кабатлау ب ك | 1 |
| 6 | Ләм, үәү хәрефләрен кабатлау ل و | 1 |
| 7 | Һә, фә хәрефләрен кабатлау ه ف | 1 |
| 8 | Каф, шин хәрефләрен кабатлау ش ق | 1 |
| 9 | Син, сакау сә хәрефләрен кабатлау س ث | 1 |
| 10 | Сад, та хәрефләрен кабатлау ص ط | 1 |
| 11 | Җим, ха, хә хәрефләрен кабатлау خ ج ح | 1 |
| 12 | Гайн, гәйн хәрефләрен кабатлау ع غ | 1 |
| 13 | Дәл, дад хәрефләрен кабатлау ض د | 1 |
| 14 | Зәл, за хәрефләрен кабатлау ذ ظ | 1 |
| 15 | Кабатлау (сүзләрне йөгерек уку) | 1 |
| 16 | Мәд хәрефләре ى و ا | 2 |
| 17 | Тәшдидле хәрефләр | 2 |
| 18 | Тәнвинле хәрефләр | 2 |
| 19 | Тәнвинле тәшдид | 1 |
| 20 | Әлиф һәм һәмзә | 2 |
| 21 | Тә-марбута ة | 2 |
| 22 | Васл | 1 |
| 23 | Вакыф | 1 |
| 24 | Мәдд-сузу | 1 |
| 25 | Идгам | 1 |
| 26 | Иклаб | 1 |
| 27 | Калькалә ق ط ج د ب | 1 |
| 28 | Изһар | 1 |
| 29 | Ихфа | 1 |
| 30 | Кабатлау | 1 |
| | Барлыгы | 35 |

# ГЫЙБАДӘТ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Ислам дине турында мәгълүмат бирү. Гамәл кылу | 1 |
| 2 | Галәмнәрнең Раббысы Аллаһ | 1 |
| 3 | Исламда сәлам бирү | 1 |
| 4 | Ислам диненең 5 баганасы. Аның әһәмияте. | 1 |
| 5 | Намаз. Гомуми мәгълүмат. Намаз әдәбе. Намазның шартлары. | 1 |
| 6 | “Тәһарәт” төшенчәсе. Фазыйләтләре. Әдәбе | 1 |
| 7 | Мөхәммәт саләллаһу гәләйһи вәссәләм минем өчен үрнәк | 1 |
| 8 | Адәм гәләйһиссәләм. Ибраһим гәләйһиссәләм | 1 |
| 9 | “Әл-Фәтиха”, “Сәнә”, “Ихлас”, “Кәүсәр” сүрәләрен кабатлау | 1 |
| 10 | “Әттәхият”, “Салават”, “Раббәнә”, “Сәлам” догаларын кабатлау | 1 |
| 11 | Гыйлем алу һәр мөселманның бурычы (хәдис) | 1 |
| 12 | Кыйбла. Азан. Азан догасы | 1 |
| 13 | Мөселманнарның изге китабы - Коръән | 1 |
| 14 | Нәрсә ул иман? (Иман шарты) | 1 |
| 15 | Иртәнге намаз | 1 |
| 16 | Ватанны сөю иманнан | 1 |
| 17 | Өйлә намазы | 1 |
| 18 | Аятел Көрси | 2 |
| 19 | Икенде намазы | 1 |
| 20 | Дүрт тугъры хәлифә (“Чәһәр ярлар”) | 1 |
| 21 | Азан. Азан догасы | 1 |
| 22 | Ахшам намазы | 1 |
| 23 | Исламда дүрт мәзһәб | 1 |
| 24 | Ястү намазы. Конут догасы | 2 |
| 25 | Тәсбих һәм зекер әйтү фазыйләте. “Тәкаббәл” догасы | 2 |
| 26 | Аллаһтан килгән хәбәр - вәхий | 1 |
| 27 | Бәдрәфкә керү һәм чыгу догалары | 1 |
| 28 | Мәчеткә керү һәм чыгу догалары | 1 |
| 29 | Зиратка керү догасы | 1 |
| 30 | Ашаганчы һәм ашаганнан соң укый торган догалар | 1 |
| 31 | Өйдән чыкканда укый торган дога | 1 |
| 32 | Мәҗлестә укыла торган дога | 1 |
| | Барлыгы | 35 |

## III МУСТӘВӘ

## КОРЪӘН ӘЛИФБАСЫ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ

| **Дәрес** | **Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|---|
| 1 | Гарәп теле турында кыскача мәгълүмәт. Гарәп язуының үзенчәлекләре. Хәрәкәләр. ا ر ز م хәрефләрен кабатлау | 1 |
| 2 | ت ن ى ب хәрефләрен кабатлау | 1 |
| 3 | و ه ك ل хәрефләрен кабатлау | 1 |
| 4 | ف ق ش س хәрефләрен кабатлау | 1 |
| 5 | ط ج ث ص хәрефләрен кабатлау | 1 |
| 6 | ح غ ع خ хәрефләрен кабатлау | 1 |
| 7 | ظ د ض ذ хәрефләрен кабатлау | 1 |
| 8 | Тәшдидле хәрефләр. Тәнвинле хәрефләр. Тәнвинле тәшдид | 1 |
| 9 | Кояш һәм ай хәрефләре | 1 |
| 10 | Васл .Вакыф | 1 |
| 11 | Нүн сәкен кагыйдәләре. Изһар кагыйдәсе | 1 |
| 12 | Идгам кагыйдәсе | 1 |
| 13 | Иклаб кагыйдәсе | 1 |
| 14 | Ихфа кагыйдәсе | 1 |
| 15 | Тәксирин тәнвин | 1 |
| 16 | Мим сәкен хөкемнәре. Идгам мисләйни мәгәл гуннә | 1 |
| 17 | Ихфа шәфәвия | 1 |
| 18 | Изһар | 1 |
| 19 | Идгам төрләре. Идгам мисләйни | 1 |
| 20 | Идгам мүтәҗәнисәйн | 1 |
| 21 | Идгам мүтәкарибәйн | 1 |
| 22 | Озын сузыклар хөкемнәре. Мәдд табигый | 1 |
| 23 | Мәдд муттасыйл | 1 |
| 24 | Мәдд мунфәсыйл | 1 |
| 25 | Мәдд ләзем | 1 |
| 26 | Мәдд гарыз | 1 |
| 27 | Мәдд лин | 1 |
| 28 | Ра хәрефе хөкемнәре | 1 |
| 29 | ЛәфзатуЛлаһ | 1 |
| 30 | Калкалә | 1 |
| | Барлыгы | 30 |

## ГЫЙБАДӘТ ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Ислам дине. 5 баганасы. Галәмнәрнең Раббысы Аллаһ | 1 |
| 2 | Шәһадәт кәлимәсе. Мәгънәсе | 1 |
| 3 | “Тәһарәт” төшенчәсе. Фазыйләтләре. Әдәбе. Фарызлары | 1 |
| 4 | Тәяммүм. Фарызлары | 1 |
| 5 | Намаз. Гомуми мәгълүмат. Намазның шартлары. | 1 |
| 6 | Намаз вакытлары | 1 |
| 7 | Намазның тышкы фарызлары | 1 |
| 8 | Намазның эчке фарызлары | 1 |
| 9 | Иман. Иман шарты. Фарызлары | 1 |
| 10 | Мәчет – Аллаһ йорты | 1 |
| 11 | Гыйлем алу һәр мөселманның бурычы (хәдис) | 1 |
| 12 | Кыйбла. Азан. Азан догасы | 1 |
| 13 | Мөселманнарның изге китабы - Коръән | 1 |
| 14 | Госел. Фарызлары | 1 |
| 15 | Кем ул имам, мөхтәсиб, мөфти? | 1 |
| 16 | Хәдис. Мәгънәсе | 1 |
| 17 | Дүрт тугъры хәлифә (“Чәһәр ярлар”) | 1 |
| 18 | Аятел Көрси | 1 |
| 19 | Ястү намазы. Конут догасы | 1 |
| 20 | Тәсбих һәм зекер әйтү фазыйләте. “Тәкаббәл” догасы | 1 |
| 21 | “Әл-Фәтиха” сүрәсенең тәфсире | 2 |
| 22 | Кәлимәтү-т-тәүхид | 3 |
| 23 | Кәлимәтү раддил-күфри | 2 |
| 24 | Кәлимәтү-л-истигъфәр | 2 |
| 25 | Кәлимәтү-т-тәмҗид | 2 |
| 26 | Иман мүҗмәл | 2 |
| 27 | Иман муфәссал | 2 |
| | Барлыгы | 35 |

**ӘДӘП-ӘХЛАК ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ ТЕМАТИКАСЫ (I-III МУСТӘВӘ)**

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Сәламләшү әдәбе | 1 |
| 2 | Мәчет әдәбе | 1 |
| 3 | Ашау әдәбе | 1 |
| 4 | Йокыга яту һәм йокыдан тору әдәбе | 1 |
| 5 | Олыларны хөрмәт итү | 1 |
| 6 | Чисталык – ярты иман (тәһарәт, бәдрәф әдәбе) | 1 |
| 7 | Сәфәр әдәбе | 1 |
| 8 | Дуслык, татулык | 1 |
| 9 | Йорт әдәбе | 1 |
| 10 | Тырышлык – ялкаулык | 1 |
| 11 | Әти-әни хакы | 1 |
| 12 | Туганлык хакы | 1 |
| 13 | Авыруның хәлен белү | 1 |
| 14 | Күрше хакы | 1 |
| 15 | Мәрхәмәтлелек | 1 |
| 16 | Гаделлек, әманәт | 1 |
| 17 | Гыйлем әдәбе | 1 |
| 18 | Юмартлык, ярдәмләшү | 1 |
| 19 | Дөреслек һәм ялган | 1 |
| 20 | Сабырлык | 1 |
| 21 | Урлашу | 1 |
| 22 | Тугрылык | 1 |
| 23 | Шөкер кылу | 1 |
| 24 | Сөйләм әдәбе | 1 |
| 25 | Хайваннарга, кошларга мәрхәмәтле караш. Табигатьне саклау | 1 |
| 26 | Көнчелек, мактану | 1 |
| 27 | Туган илне, туган телне ярату | 1 |
| 28 | Һәр изгелек сәдакә | 1 |
| 29 | Исраф | 1 |
| 30 | Батырлык, куркаклык | 1 |
| 31 | Тәккәберлек – тыйнаклык | 1 |
| 32 | Кибет, базар әдәбе | 1 |
| 33 | Кешеләрне хөрмәт итү, ярату | 1 |
| 34 | Дини бәйрәмнәр | 1 |
| 35 | Кем ул тәрбияле бала? | 1 |
|  | Барлыгы | 35 |

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Мөгаллим сәни.
2. Язу дәфтәре.
3. Ислам дине нигезләре – Казан: “Хозур” – “Тынычлык” нәшрият йорты, 2017. – 608 б.
4. Тәҗвид. Коръән уку кагыйдәләре. Г.Харисова., Казан., 2007 ел.
5. Җәлил хәзрәт дәресләре. Казан, 2012 ел.
6. Ислам тәрбиясе. К.Вәлиуллин., Казан., 2012 ел.

**Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга**
**рухи-әхлакый тәрбия бирү**
**программасы**

Атна дәвамында йөрүче
3 - 7 яшьлек балалар өчен

# 1. АҢЛАТМА ЯЗУЫ

## 1.1. Программа түбәндәгеләргә нигезләнеп төзелгән:

• “Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында” 26.09.1997 ел, №125-ФЗ Федераль закон һәм Татарстан Республикасы мөселманнарының Үзәк Дини оешмасы – Диния нәзарәте Уставы нигезендә, “Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” гы Федераль закон.

• Бала хокуклары турында конвенция (13.12.1989 ел);

• Россия Федерациясе Гаилә Кодексы;

• СанПин 2.4.1.3079-13 СанПин мәктәпкәчә белем бирү санитар-эпидемиологик кагыйдәләре һәм нормативлары (Россия Юстиция министрлыгында 2014 елның 20 августында № 33660 теркәлгән)

• Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Балтач районы мөхтәсибәте Балтач Үзәк мәчете Уставының 2,3 бүлегенең “е” бүлекчәсе.

• “Мәчет каршындагы курслар өчен дини тәрбия программасы” / төзүчеләр: Валиуллин Камил Хәмзә улы, Курамшин Ришат Исмәгыйл улы – Казан 2019.-103 б.

• Гаиләдә, балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен / төзүчеләр: К.В. Закирова, Р.А. Низамов – Казан : Мәгариф, 2005. – 22 б.

Балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү – кешелек дөньясы алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе. Кешенең әхлагы булмаса, ул үзе дә, аның тирә-ягындагылары да бәхетсез була. Кызганычка каршы, бүгенге көндә бу проблема көн кадагына сугылган проблемаларның берсе. Җәмгыятебез социаль һәм икътисадый үзгәрешләр кичергән заманда, шәхеснең белемлелеге белән тәрбиялелеге арасында бәйләнеш өзелде кебек. Балаларның үз-үзләрен тотышларындагы тупаслыклар, кешеләр белән аралашуларындагы кимчелекләр һәммәбезне борчый. Мәгълүм ки, кешене яман эшләрдән белемлелек түгел, бәлки әхлак тәрбиясе, әдәплелеге, намуслылыгы саклый. Әхлак булганда гына тәрбияче көтелгән нәтиҗәләргә ирешә ала.

Татар халкының күп гасырлар буенча тупланып, үсеп, камилләшеп килгән әхлакый һәм рухи тәрбия кануннарын гомумиләштереп, “халык педагогикасы” дигән төшенчәгә кертергә мөмкин. Нәкъ менә шушы халыкчан методика тәрбия эшендә безгә ныклы таяныч була ала. Заман бүген безнең алда һаман үзгәреп торучы шартларда яшәргә, эшләргә, тормышта үз урынын табарга сәләтле шәхес тәрбияләү кебек катлаулы бурычларын куя. Милли мәгарифне үстерүдә Риза Фәхреддиннең педагогик хезмәтләреннән файдалансак бик отышлы булыр. Чөнки галимнең өйрәтүләре бүгенге заман таләпләренә дә туры килә. Ислам кыйммәтләрен балаларга рухи-әхлакый белем бирүдә куллану бик отышлы. Балаларда Аллаһ Тәгаләгә, Пәйгабәребез Мөхәммәд гәләйһиссәләмгә, эти- әнигә карата мәхәббәт тәрбияләү – әхлак тәрбиясенең нигезе.

Ризаэддин Фәхретдиннең зирәк сүзләрен яшь буынга тәрбия бирүдә девиз итеп алырга мөмкин: “Бала чакта алган тәрбияне соңрак бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас”.

**Максат:**

Балаларга дин турында башлангыч төшенчәләр бирү; Ислам диненең рухи-әхлакый кыйммәтләре белән таныштыру; балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү; татар халкының тәрбияви гореф-гадәтләре белән таныштыру.

**Бурычлар**:

1. Балаларда Ислам диненең кыйммәтләренә кызыксыну уяту, аларны белергә теләк, омтылыш булдыру;
2. Ислам дине кыйммәтләре нигезендә рухи-әхлакый сыйфатлар булдыру;
3. Нәниләрнең уй-фикер сәләтен үстерү, дөньяны танып белү даирәсен киңәйтү;
4. Акыл эшчәнлеген үстерү;
5. Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлылыкларын арттыру;
6. Сөйләмнәрен баету, фикерләрен нигезләп әйтә, сөйли белергә өйрәтү;
7. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша балаларда Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү.

Программага темалар киләчәк яшь буынны мәрхәмәтле, шәфкатьле, туган як табигатен саклаучы һәм яратучы, гомум кешелекнең уңай сыйфатларына ия булган, милләт мәнфәгатен яклардай шәхес итеп тәрбияләү бурычлары күз алдында тотып сайланган.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләү уенга нигезләнгән, уенчыл характерда язылырга тиеш. Чөнки бала уен уйнап яшәеш, кешеләр һәм хезмәт белән таныша. Уен барышында аның әхлакый-психологик сыйфатлары һәм ихтыяр көче формалаша, рухи һәм физик яктан үсә. Бу яшьтәге балалар таныш сүзләр аша эмоциональ югарылыктагы әсәрләрне яраталар, аларны җиңел такмаклар, аваз ияртемнәре, сюжетлы шигырьләр, әкиятләр, кыска күләмле маҗаралы әсәрләр һәм тизәйткечләр кызыксындыра.

Әхлак шөгылләрендә халык авыз иҗаты әсәрләрен, халкыбызның мөнәҗәтләрен, сынлы сәнгать өлкәсендә мәгълүматны бирү кирәк.

Балаларны халкыбызның бөек шагыйрьләре Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Муса Җәлил әсәрләре белән таныштырып, шәхесләргә карата балалар күңелендә чиксез хөрмәт, ә иҗатларына карата зур кызыксыну хисләре тәрбияләнә, балаларның күңелендә милләтебез белән горурлану хисләре уята.

### 1.2. Ислам кыйммәтләрен бирү аша балаларда түбәндәге рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләнә:

- Аллаһның күркәм исем-сыйфатларын белү. Аллаһны тану һәм ярату. Ислам диненең нигезләрен, гадәтләрен саклау. Аллаһ Тәгалә йортлары – мәчетләрне ярату, ихтирам итү.

- Пәйгамбәребез гәләйһиссәләмнең сирасын, сәхабаларның тормышларын өйрәнү, алар тормышыннан дәресләр, файдалар алу.

- Коръән Кәримгә мәхәббәт уяту һәм аны дөрес укырга өйрәнү, аңа карата хөрмәт тәрбияләү.

- Балаларны Коръән Кәримдә зекер ителгән пәйгамбәрләр кыйссалары белән тәрбияләү, аларның тормышлары үрнәгендә балаларда яхшы сыйфатлар тәрбияләү.

- Әти-әнигә карата мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү. Кушканнарын тыңлау, хезмәткә хөрмәт формалаштыру. Гаиләнең кадерлелеген аңлату.

- Үз милләтеңне, Ватаныңны ярату. Үз милләтеңә, туган телеңә хөрмәт тәрбияләү. Милләтеңнең тарихын, мәдәни мирасын белү. Туганнар, күршеләр, дуслар белән аралашу кагыйдәләрен, формаларын күрсәтү.

- Чисталык әдәпләрен бирү. Үзеңнең тәнеңне, киемеңне, бүлмәңне, йортыңны, әйләнә-тирә табигатьне чиста тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

- Сәламәтлекнең кадерен белү. Хәрамнан тыелу, хәләл ризык белән генә туклану.

**1.3. 3 яшьтән - 7 яшькә кадәрге балаларга әхлак тәрбиясе бирү программасы түбәндәге шөгелләрне үз эченә ала**:

- **Рухи хәзинә.** Үз эченә иман дәресләре, пәйгамбәребез Мөхәммәд гәләйһиссәләмнең тормыш юлы, пәйгамбәрләр тарихын ала. Темалар һәр елны кабатлана, яшь үзенчәлекләренә карап катлауландырыла, тирәнәйтелеп тулыландырыла.

- **Коръән әлифбасы**:

4-5 яшьлекләр: гарәп хәрефләре белән танышу, темага туры килгән рәсемнәр буяу, гарәпчә шигырьләр ярдәмендә ныгыту.

5-6 яшьлекләр: хәрәкәләр белән танышу, иҗекләр язылган карточкалар белән эшләү.

6-7 яшьлекләр: иҗекләр язылган карточкаларны кушып уку, мөгаллим сәни китабы белән таныштыру; мәдд, тәшдид, тәнвин темаларын өйрәнү. Коръән уку.

- **Гыйбадәт** (намаз уку тәртибе: кечкенәләр төркеме – 3-4 яшьлекләр өчен).

Балалар һәр көн ике намаз укый һәм Коръән кабатлый. Татарча матур итеп дога кылалар. Намаз эчендәге зекерләр, Аятел Көрси, тәсбих догасы һәр көн намаз укыганда кабатланып торганга балалар бик җиңел үзләштерәләр. Намазны өс киемнәре чиста, гаурәтләре капланган, малайлар түбәтәй киеп, Әбү Хәнифә мәзхәбе буенча укыйлар. Алдан тәһарәтне кабатлап, азан әйтеп, азан догасын кылалар. 5-7 яшьлекләр өчен гыйбадәт аерым шөгыль булып керми.

Җомга көнне “Кәхф” сүрәсенең 10 аятен яттан укыйлар.

- **Коръән ятлау**: 3 яшьтән 7 яшькә кадәр 1 җүз (20 бит) ятлауга ирешәләр. Бу шөгыльдә балалар яшь үзенчәлекләрен күздә тотып 3 төркемгә бүленәләр. Бер

бала Коръән сөйләгәндә калганнары рәсем буяп, тыңлап утыра. Бер-берсен тыңлап, аннан бергә кабатлап яхшырак истә калдыралар. Ярышып иптәшләрен узарга тырышу да зур нәтиҗәләр бирә. Шулай ук бүләкләү, мактау да кулланыла. 30нчы җүзне 4 өлешкә бүлеп, 4 агачка урнаштырыла. Беренче агачка “Фәтихә” сүрәсе һәм “Фил” сүрәсеннән алып “Нәс” сүрәсенә кадәр сүрәләр керә. Икенче агачка “Тин” сүрәсеннән “Һүмәзәһ” сүрәсенә кадәр сүрәләр керә, өченче агачка “Буруҗ” сүрәсеннән “Шарх” сүрәсенә кадәр сүрәләр керә, дүртенче агачка “Иншикак” сүрәсеннән “Нәбә” сүрәсенә кадәр сүрәләр керә. Агачта урнашкан сүрәләрне яттан сөйләп тапшырган балага бүләк бирелә. Дүрт агачны да тапшыручы балага зур, яхшы намазлык бүләк ителә. Һәр ел ахырында районда Коръән, Намаз бәйгеләре үтә, аларда да балаларыбыз бүләкле урыннар алалар.

- **Әдәп-әхлак шөгыльләре**: атнага бер әхлак темасы сайлап алына һәм бу тема атна дәвамында ачыла.

Дүшәмбе – бу тема турында гомуми мәгълүмат бирелә, бу темага кагылышлы догалар ятлыйлар.

Сишәмбе – атна темасы белән бәйләп, Аллаһның күркәм исемнәрен өйрәнәләр.

Чәршәмбе – атна темасы белән бәйләп, матур әдәбият әсәрләрен тыңлыйлар, шигырьләр ятлыйлар.

Пәнҗешәмбе – атна темасы белән бәйләп, Пәйгамбәребез гәләйһиссәләмнең хәдисләре белән танышалар.

Җомга көнне гомуми кабатлау үткәрелә.

Мәдрәсәдә шөгыльләр дәвамлылыгы 15-20 минут (яшь үзенчәлекләренә карап).

Балалар яшь үзенчәлекләренә карап, өч төркемгә бүленә:

1) Беренче төркем - кечкенәләр төркеме (3-4 яшьтәге балалар);
2) Икенче төркем – зурлар төркеме (5-6 яшьтәге балалар);
3) Өченче төркем – мәктәпкә хәзерлек төркеме (6-7 яшьтәге балалар).

## 2. РУХИ ХӘЗИНӘ

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Минем динем Ислам | 2 |
| 2 | Раббым Аллаһ | 2 |
| 3 | Иман шарты: кәлимәтү имән | 1 |
| 4 | Ислам диненең биш баганасы. | 2 |
| 5 | Шәһадәт кәлимәсе | 2 |
| 6 | Намаз | 2 |
| 7 | Ураза | 2 |
| 8 | Зәкәт. Сәдака | 2 |
| 9 | Хаҗ | 2 |
| 10 | Иман шарты: кәлимәтүт тәүхид | 1 |
| 11 | Җомга көне. Кәһф сүрәсе | 2 |
| 12 | Нәрсә ул Иман? Иманның алты нигезе | 2 |
| 13 | Җәннәт – Атабыз Адәм һәм Анабыз Һаваның төп йорты | 2 |
| 14 | Мөселманнарның изге китабы – Коръән | 2 |
| 15 | Хәләл-харам | 2 |
| 16 | Иман шарты: кәлимәтү раддиль күфри | 1 |
| 17 | Дога кылу әдәпләре | 2 |
| 18 | Ураза һәм Корбан гаете | 2 |
| 19 | Мәүлид – сөекле Пәйгамбәребез туган ай | 1 |
| 20 | Шәмаил сәнгате | 2 |
| 21 | Мөнәҗәт күңел көзгесе | 2 |
| 22 | Иман шарты: кәлимәтүл истигфәр | 1 |
| 23 | Мөхәммәд гәләйһиссәләм – Аллаһның соңгы рәсүле | 2 |
| 24 | Мөхәммәд гәләйһиссәләмнең мәрхәмәтлелеге | 1 |
| 25 | Мөхәммәд гәләйһиссәләмнең балаларга мөнәсәбәте | 1 |
| 26 | Мөхәммәд гәләйһиссәләмнең юмартлыгы | 1 |
| 27 | Мөхәммәд гәләйһиссәләмнең гаделлеге | 1 |
| 28 | Мөхәммәд гәләйһиссәләмнең сабырлыгы | 1 |
| 29 | Мөхәммәд гәләйһиссәләмнең батырлыгы | 1 |
| 30 | Хәдис – Мөхәммәд гәләйһиссәләм мирасы | 2 |
| 31 | Иман шарты: кәлимәтүт тәмҗид | 1 |
| 32 | Адәм гәләйһиссәләм–Аллаһның рәхмәте белән яратылган беренче кеше | 2 |
| 33 | Нух гәләйһиссәләм. Сабырлык үрнәге | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 34 | Салих гәләйһиссәләм.Тыйнаклык үрнәге | 2 |
| 35 | Ибраһим гәләйһиссәләм. Әти-әнигә мәрхәмәтлелек үрнәге | 2 |
| 36 | Исмәгыйль гәләйһиссәләм. Аллаһка буйсыну үрнәге | 2 |
| 37 | Иман шарты: имәнүм мүҗмәл | 1 |
| 38 | Йосыф гәләйһиссәләм.Тәвәккәл кылу үрнәге | 2 |
| 39 | Юныс гәләйһиссәләм.Аллаһ ризыкландыручы | 2 |
| 40 | Даут гәләйһиссәләм. Батырлык үрнәге | 2 |
| 41 | Сөләйман гәләйһиссәләм. Шөкер кылу үрнәге | 2 |
| 42 | Гайсә гәләйһиссәләм. Аллаһның бөеклек сыйфаты | 2 |
| 43 | Иман шарты: имәнүм муфассәл | 1 |
| | Барлыгы | 72 |

## 3. КОРЪӘН ӘЛИФБАСЫ

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Гарәп иленә сәяхәт. Гарәп теле турында кыскача мәгълүмәт. | 1 |
| 2 | Гарәп язуының үзенчәлекләре. Хәрәкәләр. Әлиф хәрефе белән танышу ا | 1 |
| 3 | Ра хәрефе белән танышу. Хәрәкәләрне бер-берсе белән кушып укырга өйрәнү.ر | 1 |
| 4 | Сәкен. Зә хәрефе белән танышу. ز | 1 |
| 5 | Мим хәрефе белән танышу. م | 1 |
| 6 | Тә хәрефе белән танышу. ت | 1 |
| 7 | Нүн хәрефе белән танышу. ن | 1 |
| 8 | Йәй хәрефе белән танышу. ى | 1 |
| 9 | Бә хәрефе белән танышу. ب | 1 |
| 10 | Кәф хәрефе белән танышу. ك | 1 |
| 11 | Ләм хәрефе белән танышу. ل | 1 |
| 12 | уау хәрефе белән танышу. و | 1 |
| 13 | Һә хәрефе белән танышу. ه | 1 |
| 14 | Фә хәрефе белән танышу. ف | 1 |
| 15 | Каф хәрефе белән танышу. ق | 1 |
| 16 | Шин хәрефе белән танышу. ش | 1 |
| 17 | Син хәрефе белән танышу. س | 1 |
| 18 | Сакау Сә хәрефе белән танышу. ث | 1 |
| 19 | Сад хәрефе белән танышу. ص | 1 |
| 20 | Та хәрефе белән танышу. ط | 1 |
| 21 | Җим хәрефе белән танышу. ج | 1 |
| 22 | Ха хәрефе белән танышу. خ | 1 |
| 23 | Хә хәрефе белән танышу. ح | 1 |
| 24 | Гайн хәрефе белән танышу. غ | 1 |
| 25 | Гәйн хәрефе белән танышу. ع | 1 |
| 26 | Дәл хәрефе белән танышу. د | 1 |
| 27 | Дад хәрефе белән танышу. ض | 1 |
| 28 | Зәл хәрефе белән танышу. ذ | 1 |
| 29 | За хәрефе белән танышу. ظ | 1 |
| 30 | Калькалә ق ط ج د ب | 1 |
| 31 | Озын сузыклар ( мәдд хәрефләре) ا و ى | 1 |
| 32 | Икеләтеп укыла торган хәрефләр ( тәшдид) | 1 |
| 33 | Тәнвин. Тәнвин белән тәшдиднең бергә килүе | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 34 | Тә-марбута ة | 1 |
| 35 | Һәмзә ء , кушылу (Васыл) | 1 |
| | Барлыгы | 35 |

## 4. ГЫЙБАДӘТ
### 3-4 яшьлекләр өчен

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Ислам диненең 5 баганасы. Аның әһәмияте | 1 |
| 2 | Намаз шартлары | 1 |
| 3 | Тәһарәт – пакълану чарасы | 1 |
| 4 | Тәкбир.Сәнә | 2 |
| 5 | “Әгузү”, “Бисмилләһ” | 1 |
| 6 | “Әл-Фәтиха” сүрәсенең өстенлеге | 1 |
| 7 | “Әл-Фәтиха” сүрәсе | 3 |
| 8 | “Кәүсәр” сүрәсе | 2 |
| 9 | “Ихлас” сүрәсе | 2 |
| 10 | Рөкугъ зекерләре | 1 |
| 11 | Сәҗдә зекерләре | 1 |
| 12 | Әттәхият | 4 |
| 13 | Салават | 4 |
| 14 | Раббәнә | 2 |
| 15 | Сәлам догасы | 2 |
| 16 | Аятел Көрси | 5 |
| 17 | Кабатлау. 2 рәкәгать намаз тапшыру. Тәкаббәл догасы | 2 |
| | Барлыгы | 35 |

## 5. КОРЪӘН

### 4 яшьлек балалар өчен

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Коръән Кәрим турында кыскача мәгълүмат. Коръән иңдерелү һәм кыскача тарихы | 1 |
| 2 | Коръән Кәримгә карата булган әдәпләр. Сүрә һәм аять төшенчәләре | 1 |
| 3 | “Әл-Фәтиха” сүрәсе. | 3 |
| 4 | “Әл-Ихлас” сүрәсе. | 3 |
| 5 | “Ән-Нәс” сүрәсе | 3 |
| 6 | “Әл-Фәләкъ” сүрәсе. | 3 |
| 7 | “Әл-Мәсәд” сүрәсе. | 3 |
| 8 | “Ән-Наср” сүрәсе. | 3 |
| 9 | “Әл-Кәфирун” сүрәсе. | 3 |
| 10 | “Әл-Кәүсәр” сүрәсе. | 3 |
| 11 | “Әл-Мәгун” сүрәсе. | 3 |
| 12 | “Әл-Кураиш” сүрәсе. | 3 |
| 13 | “Әл-Фил” сүрәсе. | 3 |
| | Барлыгы | 35 |

### 5-6 яшьлек балалар өчен

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Коръән Кәрим турында кыскача мәгълүмат. Коръән иңдерелү һәм кыскача тарихы | 1 |
| 2 | Коръән Кәримгә карата булган әдәпләр. Сүрә һәм аять төшенчәләре | 1 |
| 3 | “Әл-Һүмәзәһ” сүрәсе. | 3 |
| 4 | “Әл-Гаср” сүрәсе. | 2 |
| 5 | “Әт-Тәкәсүр” сүрәсе. | 3 |
| 6 | “Әл-Каригәһ” сүрәсе. | 3 |
| 7 | “Әл-Гадият” сүрәсе. | 3 |
| 8 | “Әл-Зәлзәлә” сүрәсе. | 3 |
| 9 | “Әл-Бәинәһ” сүрәсе. | 3 |
| 10 | “Әл-Кадр” сүрәсе. | 2 |
| 11 | “Әл-Галәкъ” сүрәсе. | 3 |
| 12 | “Әт-Тин” сүрәсе. | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | “Әл-Инширах” сүрәсе. | 2 |
| 14 | “Әд-Духә” сүрәсе. | 3 |
| | Барлыгы | 35 |

**6-7 яшьлек балалар өчен**

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Коръән Кәрим турында кыскача мәгълүмат. Коръән иңдерелү һәм кыскача тарихы. Коръән Кәримгә карата булган әдәпләр. Сүрә һәм аять төшенчәләре | 1 |
| 2 | “Әл-Ләйл” сүрәсе. | 2 |
| 3 | “Әл-Шәмс” сүрәсе. | 2 |
| 4 | “Әл-Бәләд” сүрәсе. | 2 |
| 5 | “Әл-Фәҗр” сүрәсе. | 2 |
| 6 | “Әл-Гашийәһ” сүрәсе. | 2 |
| 7 | “Әл-Әглә” сүрәсе. | 2 |
| 8 | “Әл-Тарикъ” сүрәсе. | 2 |
| 9 | “Әл-Буруҗ” сүрәсе. | 2 |
| 10 | “Әл-Иншикак” сүрәсе. | 3 |
| 11 | “Әт-Мутаффифин” сүрәсе. | 3 |
| 12 | “Әл-Инфитар” сүрәсе. | 2 |
| 13 | “Әт-Тәквир” сүрәсе. | 2 |
| 14 | “Гәбәсә” сүрәсе. | 2 |
| 15 | “Нәзигәт” сүрәсе. | 3 |
| 16 | “Нәбә” сүрәсе. | 3 |
| | Барлыгы | 35 |

## 6. ӘДӘП-ӘХЛАК ДӘРЕСЛӘРЕНЕҢ АТНАЛЫК ПЛАНЫ

| Атна/Тема | Гомуми мәгълүмат, догалар | Аллаһның гүзәл исемнәре | Матур әдәбият әсәрләре | Хәдисләр |
|---|---|---|---|---|
| 1атна Сәламләшү әдәбе | Сәлам – сәламәтлек , исәнлек, берәр нәрсәнең яхшы, хәерле булуын теләү дигән сүз. Мөселманнар бер-берсе белән “Әссәләму галәйкум вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү”, “Вәгаләйкумуссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү” дип сәламләшәләр. | السلام Аллаһы Тәгалә җитешсезлек һәм гаепләрдән, начар эшләрдән сәламәт булган, сәламәтлек Бирүче Зат. | 1. Госман Садә “Әссәләму галәйкум” (Иң матур сүз, 330 бит). 2. Хәйруллина Вәсимә “Хәерле көн”. (Иң матур сүз, 331 бит). | 1. “Арагызда өлфәт мәхәббәт арттырачак нәрсәне сезгә белдеримме? Арагызда сәлам таратыгыз”. 2. “Әгәр сезгә сәлам бирелсә, сез аннан да яхшырак рәвештә җавап кайтарыгыз яисә аның сәламе кебек җавап бирегез”. |
| 2 атна Мәчет әдәбе | Мәчет – ул Аллаһ хөрмәтләгән йорт. Мәчеткә керү әдәбе: 1. Уң аяк белән кереп, сул аяк белән чыгарга. 2. Мәчеттә тынычлык һәм тәртип сакларга, тыйнак булырга. 3. Шәригать кушканча | الفتاح Аллаһы Тәгалә колларына бөтен җиңеллек ишекләрен Ачучы, Җиңеләйтүче һәм нигъмәтләрен | 1. “Балаларга иң кирәкле догалар” 28-30, 35-39 бит; 2. Хәйруллина В. “Азан әйтә бер малай” (Иң матур сүз, 276 бит); 3. Вәлиева Р. “Кәләпүшем, | “Әгәр дә бер мөселман тәһарәт алып өеннән мәчеткә гыйбадәт кылырга дип чыга икән, аның сәфәре тәмамланганчы һәр адымы санынча савап өстәлеп барыр”. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | киенергә.<br>4. Мәчеткә кергәндә укыла торган дога: “Аллаһуммә фтәхли әбвәбә рахмәтик”.<br>5. Мәчеттән чыкканда укыла торган дога: “Аллаһуммә фтәхлии әбвабә фадлик”. | колларының алдына Җәюче. Бәндәләренә ризык Бирүче һәм рәхмәт капкаларын Ачучы Зат. | кәләпүш” (Иң матур сүз, 276 бит). | |
| 3 атна<br>Ашау әдәбе | Ашау әдәпләре белән таныштыру.<br>Ашар алдыннан укыла торган дога: “Аллаһуммә бәрик ләнә фиимәә разәктәнә вә кыйнә газәәбәннаар”.<br>Ашаганнан соң укыла торган дога: “Әлхәмдулилләһи лләзи әтегамәнәә вә сәкаанәә вә җәгаләнәә минәл муслимиин”. | الرزاق<br>Аллаһы Тәгалә Ризыкландыручы | 1. “Балаларга иң кирәкле догалар” ( 3-5 бит).<br>2. Рахмәт Б. “Аш вакыты” (Иң матур сүз”, 254 бит).<br>3. Батулла Р. “Чыбык ашату “ (Иң матур сүз, 205-206 бит). | 1. “Бәрәкат ризыкның уртасына иңә, һәр кешегә үз алдыннан ашау кирәк”.<br>2. “Уң кул белән ашагыз һәм уң кул белән эчегез, чөнки сул кул белән шайтан гына ашый һәм эчә”. |
| | Йокы әдәпләре белән | الحى<br>Аллаһы Тәгалә | 1. "Балаларга иң кирәкле догалар” | “Аллаһ – Аннан башка |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 атна<br>Йокыга яту һәм йокыдан тору әдәбе | таныштыру.<br>Йокыдан торган вакытта укыла торган дога :<br>“Әлһәмдүлилләһилләзи әхйәәнәә бәгъдә мәә әмәәтәнәә үә иләйһин-нушур”.<br>Йокыга ятыр алдыннан укыла торган дога:<br>“Бисмикә Аллаһүммә әмүтү үә әхйә”. | даими тере, мәңгелек, үлемсез Зат.<br>القيوم<br>Аллаһы Тәгалә кукләрне һәм җирне бер тәртиптә Тотучы һәм аның тәртибен беркем боза алмас. | (6-11 бит).<br><br>2. Галиев Ш. “Тыныч йокы” (Иң матур сүз, 103 бит). | иләһ юк. Ул мәңге тере, Ул яшәешне барлап Торучы, Ул беркайчан йокымсырамас һәм йокламас”.<br>(Бәкара, 225 аят). |
| 5 атна<br>Олыларга хөрмәт | Олыларга хөрмәт күрсәтү – динебезнең нигезе булып санала, тормышыбызның бәрәкәтен арттыра. Без өлкән кешеләрне һәрвакыт хөрмәт итәргә тиеш, чөнки бу эшне Аллаһ сөя. Алар зур тормыш тәҗрибәсенә ия, үзләренең акыллы киңәшләрен бирәләр. | الملك<br>Аллаһы Тәгалә – барча галәмнең һәм кыямәт көненең хакыйкый Патшасы | 1. “Ай-һай” (Иң матур сүз, 212 бит).<br>2. Мингалим Р. “Иң зур кеше” (Көч һәм рух тамырлары). | “Чәче агарган мөселманны хөрмәт кылу – Аллаһны хөрмәт итүдер”. |
| | Бәдрәфкә кергәндә сул аяк | النظيف | “Балаларга иң | “Дөреслектә Аллаһ яхшы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6 атна<br>Чисталык – ярты иман | белән керәсе, уң аяк белән чыгасы. Сөйләшү – әдәпсезлек. Тәһарәт – ул гыйбадәт.<br>Бәдрәфкә кергәндә әйтелә торган дога: “Аллаһуммә инни әгузү бикә минәл хубси вәл хабәис”. Бәдрәфтән чыкканда әйтелә: “Гуфраанәкә”. | Аллаһы Тәгалә Пакь һәм пакьлыкны ярата. | кирәкле догалар” 42-44 бит. | һәм яхшылыкны ярата, Пакь һәм пакьлыкны ярата, Хөрмәтле һәм хөрмәтлелекне ярата, Юмарт һәм юмартлылыкны ярата. Капка төпләрегезне чиста тотыгыз...” |
| 7 атна<br>Сәфәр әдәбе | Сәфәр догасы: “Сөбехәнәлләзи саххара ләнә һәзә вә мә күннәә ләһу мукринин вә иннәә иләә Раббинәә ләмункалибуун”. | الحفيظ<br>Аллаһы Тәгалә Саклаучы, Коткаручы. | 1. “Солтания белән күбәләк” ( Иң матур сүз, 215 бит).<br>2. Нух гәләйһиссәләм кыйссасы. | “Аллаһны исеңдә тот (онытма) һәм Аллаһ сине саклар”. |
| 8 атна<br>Дуслык, татулык, бердәмлек | Адәм баласының шатлык һәм кайгы вакытларында таяныр кешеләре үзенең дуслары, шуның өчен дусларны үзегезгә туры килә торган кешеләр арасыннан эзләгез, аларны чын күңелдән сөегез. | الودود<br>Аллаһы Тәгалә яхшы колларын Сөюче, аларга рәхмәт һәм бәракәт Ирештерүче. | 1. Алиш А. “Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар” (Иң матур сүз, 186 бит).<br>2. “Гаддар” (40 хадисов в рассказах, 15 стр.). | “Кардәшеңә елмаю да изгелектән санала”.<br>1. “Үзеңә теләгән нәрсәне, кардәшеңә дә теләми торып, берегез дә мөэмин булмас”.<br>2. “Мөселман кеше теле белән дә, кулы белән дә, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 3. Алиш А. “Чукмар белән Тукмар” (Көч һәм рух тамырлары, 43 бит). | гамәле белән дә башкаларны рәнҗетмәс”.<br>4. “Мөэмин дус итә һәм аны дус итәләр, дус итмәгән һәм аның белән дуслашмаган кешедә яхшылык булмас”. |
| 9 атна<br>Йорт әдәбе | Өйдән чыкканда укыла торган дога: “Бисмилләһи тәвәккәлтү гәләл-лЛаһи уә ләә хәүлә уә ләә күввәтә илла билләәһ”.<br>Өйгә кергәндә укыла торган дога:<br>“Бисмилләәһи уәләҗенә уә бисмилләәһи хараҗнәә уә гәләә раббинәә тәвәккәлнәә”. | **الوكيل**<br>Вәкил булучы, ышанып тапшырган әйберне, эшне җиренә җиткереп башкаручы. | 1. “Төлке белән куян” әкияте ( Балачак аланы, 450 бит).<br>2. Балаларга иң кирәкле догалар 31-35 бит. | 1. “Әгәр берегез өч мәртәбә шакып, кирәргә рөхсәт сорап та, аңа җавап булмаса кайтып китсен”.<br>2. “Үз өйләрегездән башка өйләргә кермәгез, хәтта рөхсәт сорамыйча һәм сәләм бирмичә”<br>(Нур, 27). |
| 10 атна<br>Тырышлык-ялкаулык | Ислам тырышлык дине. Дөньяда бәхетле булыр өчен, ахирәтне онытмыйча, тырышлык белән яшәргә кирәк, чөнки бу тормыш фанидыр, бик | **القوي** Көчле<br><br>**القادر** Кодрәтле | 1. Галиев Ш. “Тимерша” .<br>2. Тукай Г. “Эш беткәч уйнарга ярый”, “Кызыклы шәкерт”. | 1. “Дөнья ахирәтнең кырыдыр, ул кырга нәрсә чәчсәң, шуны урырсың”.<br>2. “Дөнья өчен һич үлмәс кебек тырыш, ахирәт өчен иртәгә үләчәк кебек |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тиз үтеп китәчәк. Дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле яшәү мөселманның хакыдыр. | | | тырыш”. |
| 11 атна<br>Әти-әни хакы | Бу дөньяда безнең иң якын кешеләребез – безнең әти-әниләр. Безнең бурыч аларны ярату, хөрмәтләү, зурлау, догада булу. | الرحمن<br>Аллаһы Тәгалә бу дөньяда барча мәхлүкатына (аермасы юк ул кеше имансызмы яисә мөселманмы) мәрхәмәтле булыр.<br>الرحيم<br>Кыямәт көнендә мөэминнәрне генә рәхмәт күләгәсенә Алучы, Ярлыкаучы. | 1. Яруллин Ф. “ Кояштагы тап”.<br>2. “Өч кыз” татар халык әкияте.<br>3. “Ялгышу” (Мин динемне яратам, 68 бит).<br>4. Балаларга иң кирәкле догалар 13-16 бит. | 1. “Җәннәт әниләрнең аяк астында”.<br>2. “Әти- әниегез картлык көненә ирешсә, аларга “уф” дип тә әйтмәгез”.<br>3. “ Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр”. |
| | Туганнар әти-әниләрдән соң иң якыннары. Шуның | المهيمن | 1. “Тату туганнар” (Балачак аланы, 224- | 1. “Туганнарның хакларын үтә...” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 атна<br>Туганлык хакы | өчен алар белән һәрвакыт әдәпле һәм мәрхәмәтле булырга кирәк. Аларның һәр изге эшләрендә ярдәмче булыгыз. Сүзегез һәм эшегез белән аларга ихласлы булыгыз. | Аллаһы Тәгалә галәмнәрдәге һәр бөртекне, һәр мәхлукне гамәлләре, әҗәлләре, ризыклары белән Белүче, колларын Яклаучы һәм Саклаучы. | 225 бит).<br>2. “Алтын бөртекләр” (Балачак аланы, 215-216 бит).<br>3. “Хәмзә гафу итәргә өйрәнә” (Пәйгамбәрләр тормышы үрнәгендә, 4-14 бит). | (“Исра”, 26).<br>2. “Ризыгы киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен”. |
| 13 атна<br>Толерантлык. Мөселман булмаган башка милләт һәм дин кешеләренә түбәнсетеп карамау, алар белән күркәм мөнәсәбәттә булу. | 16 ноябрь – халыкара толерантлык көне. Толерантлык – ул кешеләргә карата түземле, кешелекле, шәфкатьле булу; икенче милләт вәкилләренә карата түземлелек, хөрмәт дип атала.<br>Татарстан Республикасы да күп милләтле халык. Биредә татарлар, руслар, удмуртлар, чуашлар, башкортлар һәм башка | الحميد<br>Аллаһы Тәгалә һәр мәхлүк тарафыннан макталган, зекер ителгән Зат һәм изгелек кылучыларны Мактаучы. | “Хикмәтле чиләк” (Балачак аланы, 378-379 бит). | “Әй, мөэминнәр, бер кавем икенче кавемне кимсетмәсен, ул кавем яхшырак булуы ихтимал” ( Хуҗурат, 11).<br>“Башка милләт (дин) кешесенә начарлык кылучы мөселманны үзем кыямәт көнендә җавапка (җәзага) тартырырмын”. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бик күп милләт халкы яши. Иманлы кеше үз милләтенә дә түбәнсенеп карамас, башка милләтне дә хөрмәт итәр. | | | |
| 14 атна<br>Күрше хакы | Күрше дип – кем белән дә булса якында гына яки янәшәдә, каршыда яшәүче кеше атала. Без күршеләрне хөрмәт итәргә, булышырга һәм хакларын үтәргә тиеш, чөнки Аллаһ мондый гәмәлләрне ярата. | **العزيز**<br>Аллаһы Тәгалә Көчле, Куәтле. Ул бөтен яктан Бердәнбер һәм аннан башка һичбер нәрсә дә булмас. | “Икмәк сыныгы” (40 хадисов в рассказах, 40-41 стр.). | 1. “Күршеңә изгелек ит, мөэмин булырсың”.<br>2. “Аллаһы Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иман китергән кеше күршесен хөрмәт итсен”. |
| 15 атна<br>Мәрхәмәтлелек | Аллаһ Тәгалә үзенең колларына Мәрхәмәтле һәм Шәфкатьледер. Шул сәбәпле мөселманнар да бер-берләренә мәрхәмәт күрсәтеп, кайгыларын, шатлыкларын уртаклашып, ярдәмләшеп яшиләр. | **الوهاب**<br>Аллаһы Тәгалә колларына санап бетермәслек күп нигъмәтләр Бирүче. | 1. Исхак Ә. “Беренче рәхмәт”.<br>2. “Өч кыз” татар халык әкияте. | “Аллаһ Тәгалә үзенең рәхмәтен йөз өлешкә аерды. Туксан тугыз өлешен үз янында калдырып, бер өлешен генә җир йөзенә төшерде”. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 16 атна<br>Гаделлек | Гаделлек – хаклыкка һәм тугрылыкка омтылу, золымны ташлап, хакны хак иясенә тапшыру, эшләребездә, гамәлләребездә һәм сүзләребездә дөрес юлны эзләү дигән сүз ул. | العدل<br>Аллаһы Тәгалә гаделлек иясе. | 1. “Көтүче һәм аның әти-әнисе” (Маленький мусульманин, 52-53 бит.).<br><br>2. “Ике аю баласы” | 1. “Гадел кешеләр Кыямәт көнендә нурдан ясалган мендәрдә торырлар”.<br>2. “Кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә җиде төрле кешене үзенең күләгәсе астына яшерер, шуларның берсе – гадел җитәкче”. |
| 17 атна<br>Гыйлем әдәбе | Әбү Дарда р.г.: “Гыйлем иясе, гыйлем алучы яки гыйлемне тыңлаучы бул, ләкин дүртенчесе булма, һәлак булырсың”. Мөселман кешегә туганнан алып, үлгәнче гыйлем алу фарыз, чөнки Аллаһ гыйлем алуны фарыз кылды (кушты). | العليم<br>Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәне Белүче, белүенең чиге юк. Элек булганнарны да, хәзер булып торганны да. Ул ачык һәм яшерен һәрнәрсәне белер. | 1. М.Хәсәнов “Сара мәктәпкә бара”.<br>2. Тукай Г. “Һәркем эштә” (Балачак аланы, 401 бит).<br>3. Б.Рәхмәт “Мәктәпкә” (Балачак аланы, 533 бит). | 1. “Бишектән алып, ләхеткә кадәр белем өйрән һәм тырышып хезмәт ит”.<br><br>2. “Әгәр бер кеше гыйлем алу нияте белән өеннән чыгып китсә, ул әйләнеп кайтканчы, Аллаһның бөтен фәрештәләре, бөтен мәхлукаты, хәтта судагы балыклар да бу кеше өчен хәер-дога кылып торырлар”. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 атна Юмартлык, ярдәмләшү | Юмартлык – үзеңә нинди дә булса, файда килүне өмет итмичә, мохтаҗларга, авыручыларга, мөмкинлекләре чикле булган кешеләргә ярдәм итү. Кеше бу дөньяда башкаларның ярдәменә мохтаж, шуның өчен динебез үзара ярдәмләшүне фарыз кылган. Динебездә иң юмарт кеше ул – Мөхәммәд гәләйһиссәләм. | **الكريم**<br>Аллаһы Тәгалә бик Юмарт. Ул юмартлыгы белән Гафу итүче, колларының эшләгән гөнаһларына карамыйча, аларга нигъмәтләр насыйп Итүче. | 1. Гыйззәтуллин Р. “Айсылу” ( Көч һәм рух тамырлары, 91 бит)<br>2. Ишморатова Р. “Яңа чана” ( Көч һәм рух тамырлары, 88-89 бит). | “Шик тә юк, юмарт кеше Аллаһка, кешеләргә һәм җәннәткә якын, җәһәннәмнән ерактыр. Саран кеше исә Аллаһтан, кешеләрдән, җәннәттән ерак, җәһәннәмгә якындыр”. |
| 19 атна Дөреслек-ялган | Җир йөзендә матур яшәр өчен Аллаһ илаһи кануннар булдырды. Шуларның берсе дөреслек, тугрылык. Пәйгамбәрләр барысы да дөреслекне генә алып килделәр. Ялган динебездә тыелган, харам | **الغفور**<br>Аллаһы Тәгалә гафу Итүче. | 1. Алиш А. “Алдакчы Наил” (Тәмле сүз, 68-69 бит).<br>2. “Дөресен сөйләү җиңел” (Пәйгамбәрләр тормышы үрнәгендә, 66-72 бит).<br>3. “Алдакчылар” | “Ялган сүздән сакланыгыз” (“Хаҗ”, 30).<br><br>“Әй, мөэминнәр! Сөйләгән вакытта чын дөресен генә сөйләгез” (“Әхзәб”, 70).<br><br>“Ялганнан сакланыгыз, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гамәл. Ул башкаларны алдар өчен, дөреслеккә туры килмәгән сүзләр сөйләү дигәнне аңлата. | | (Пәйгамбәрләр тормышы үрнәгендә, 73-77 бит). | чөнки иман бер якта, ялган икенче яктадыр. Ялган белән иман бер үк кешедә тормас". |
| 20 атна Сабырлык | Сабырлык ул түзем булу, авыр хәлләр килгәндә чыдам булып, үз-үзеңә хуҗа булу. Шатлык вакытында шөкер, кайгы вакытында сабыр булу мөселманнар өчен фарыздыр. | الصبور<br>Аллаһы Тәгалә сабырлыкка тиңе булмаган Зат. | 1. "Сабыр итә бел" (Балачак аланы, 240 бит).<br>2. "Сабырлык – җәннәт ачкычы" (Пәйгамбәрләр тормышы үрнәгендә, 55-62 бит). | "Бары тик сабыр итүчеләргә хисапсыз әҗер-саваплар булачак" ("Зүмәра", 10).<br><br>"Сабыр итүчеләрнең урыны – җәннәттер".<br><br>"Көрәштә көндәшләрен җиңгән кеше түгел, ә нык ачуланган хәлдә дә, сабыр итеп үз ачуын җиңә алган кеше көчле булып санала". |
| 21 атна Урлау | Урлау – башкаларның малын яки акчасын рөхсәтсез яки яшерен рәвештә алу. Урлау динебездә харам санала. Аллаһка ышанган кеше, Аның күреп торуын | السميع<br>Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне Ишетүче һәм аның ишетүе чиксез, ишетми калган бер | 1. Г.Тукай "Су анасы".<br>2. "Чит кеше чиясе" (Балаларга иң кирәкле догалар, 19-21 бит). | "Аллаһка ышанган кеше калебендә иманы булган хәлдә урламас". |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белеп, беркайчан да урламас. | нәрсәсе дә булмас<br>البصير<br>Аллаһы Тәгалә бөтен нәрсәләрне Күрүче һәм Күзәтүче (ачыкмы ул яки яшеренме) | | |
| 22 атна<br>Тугрылык | Тугрылык – сүзләребездә, эшләребездә һәм хәрәкәтләребездә дөрес булу дигән сүз. Тугры кеше ялган сөйләмәс, башкаларга карата хәйлә кормас. Аллаһ тугрылыкны мөселманнарга фарыз кылган. | اللطيف<br>Аллаһы Тәгалә бәндәләргә бихисап йомшаклык, шәфкать Итүче, тормышларын Җиңеләйтүче, Тәрбияләүче Зат. | 1. “Аллаһка тугрылык” (Пәйгамбәрләр тормышы үрнәгендә, 39-46 бит). | “Әй, мөэминнәр! Аллаһтан куркыгыз һәм тугрылар белән бергә булыгыз” (“Тәүбә”,19).<br>“Тугры булыгыз, чөнки ул игелек белән бергә йөри һәм аларның икесе дә җәннәттә була. Ялганнан сакланыгыз, чөнки ул яманлык белән бергә йөри һәм аларның икесе дә җәһәннәмдә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | була”. |
| 23 атна<br>Шөкер кылу | Шөкер итү – кеше үз хәленнән канәгать булып, Аллаhка рәхмәтләрен белгертү. Шөкер Аллаhны зурлау, олылау ул, Ул биргән нигъмәтләрнең кыйммәтләрен аңлап, аларны Аллаh юлында куллану. | الشكوُر<br>Аллаhы Тәгалә шөкер Итүче, олуг бүләкләр белән Бүләкләүче. | 1. “Автомобиль” (40 хадисов в рассказах, 77-78 бит). | “Әгәр нигъмәтләремә шөкер итсәгез, нигъмәтемне сезгә арттырырмын, әгәр көферлек кылсагыз, Минем газабым каты” (“Ибраhим”, 7).<br><br>“Бер кеше үзенә игелек кылучы кешеләргә шөкер кылмаса, Аллаhы Тәгаләгә шөкер кылмаган булыр”. |
| 24 атна<br>Сөйләм әдәбе | Без төрле кешеләр белән аралашабыз. Мөселманнарга әдәп саклап, тыныч hәм салмак кына сөйләшү күркәм санала. | الخالق<br>Аллаhы Тәгалә галәмдәге бөтен нәрсәне юктан бар Итүче. | А.Әхмәт “Малайлар аңламадылар” (Тәмле сүз, 46-47 бит).<br>Ә. Бикчәнтәева “Тәмле сүз” (Тәмле сүз, 38-39 бит). | “Иманлы кеше тупас, әшәке, әхлаксыз hәм азгын кеше булырга тиеш түгел”.<br>“Кешеләр белән сөйләшкәндә тәкәбберләнеп, янын белән сөйләшмә hәм җир өстендә масаеп йөрмә, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | чөнки Аллаһ үзе-үзенә исе китеп, мактанып йөрүчеләрне сөйми”. |
| 25 атна Хайваннарга, кошларга мәрхәмәтле караш. Табигатьне саклау. | Табигать – ул безнең йортыбыз. Без табигатьтән башка яши алмыйбыз. Безне кояш җылыта. Су кешеләргә дә, үсемлекләргә дә, хайваннарга да кирәк. Табигать безгә азык, кием, торак бирә. Урман безгә агач, җиләк-җимеш, гөмбә, дару үләннәре үстерә. Без табигатьне сакларга тиешбез, чөнки Аллаһ табигатьне саклаучыларны ярата. | **البارئ**<br>Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәнең үрнәге, охшашы булмаган итеп бар Итүче.<br>**المصور**<br>Аллаһы Тәгалә мәхлүкларга сурәт Бирүче. | 1. “ Агачлар да авырый” ( Балачак аланы , 177-178 бит).<br>2. “ Колючка” ( 40 хадисов в рассказах, 9-10 бит).<br>3. “ Ак песи” (Уку китабы 3 сыйныф 26-27 бит).<br>4. “ Упрямство Биляля”<br>( Крепость маленького мусульманина 23-25 стр.).<br>5. “Маленький мусульманин” 54-55 б. | “Бер хатын газап кылынды: сәбәбе бер мәчене ябып тотуы булды, мәчене ашатмады, эчертмәде, җирдә булган бөҗәкләр белән ризыкланыр өчен дә азат итеп җибәрмәде”.<br>“Бер мөселман ашлык чәчсә, я агач утыртса, җимешләрен кешеләр яисә кошлар һәм хайваннар ашаса, шуларның ашаганы аның өчен сәдакә булыр”.<br>“Барлык мәхлук (табигать) Аллаһның гаиләсе. Аллаһка иң сөекле булган кеше, Аның мәхлүгына (табигатькә) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | файдалы булганыдыр”. |
| 26 атна Мактану, көнчелек | Көнчелек – кемнең дә булса байлыгыннан, нигъмәтеннән, аның эшләреннән сәбәпсез көнләү, аның юкка чыгуын, югалуын теләү. | الغفار Аллаһы Тәгалә гөнаһ-хаталарны, тәүбә итүчеләрне гафу Итүче, тәүбәләрне кабул Итүче. | 1. А. Алиш “Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык” (Тәмле сүз 76-77 бит).<br>2. “ Мичкә белән чиләк”, “ Борын “ (Көч һәм рух тамырлары).<br>. “ Мактанчык” (Балаларга иң кирәкле догалар 31-33 бит).<br><br>4. Йосыф Гәләйһиссәләм кыйссасы. | “Кешеләр белән сөйләшкәндә тәкәбберләнеп, аның белән сөйләшмә һәм җир өстендә масаеп йөрмә, чөнки Аллаһ үзе-үзенә исе китеп, мактанып йөрүчеләрне сөйми”. (Локман, 18)<br><br>“Ут, утыннарны ашап бетергән кебек, көнчелек тә эшләнгән изгелекләрне, савапларны ашап бетерер”.<br><br>“Бөтен кешеләр дә көнчедер. Ләкин, кулы һәм теле белән көнләүне күрсәтмәсә, ягъни уртага чыгармаса, бу көнчелек кешегә зарар итмәс”. |
| 27 атна | Туган илгә, туган җиргә карата булган әдәпләр белән таныштыру. | الخبير Аллаһы Тәгалә галәмдә булган һәм | Г. Тукай “Туган тел” ( И матур сүз, 219 б). | 1. “Әй, мөэминнәр, бер кавем икенче кавемне кимсетмәсен, ул кавем |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Туган илне, туган телне ярату | Һәрбер кешегә Аллаһ Тәгалә әти-әнине биргән кебек, туган телен дә биргән. Туган җирне һәр кешегә Аллаһ газиз итеп яраткан. Без туган авылыбызда яшәвебез белән горурланабыз, Аллаһка шөкер итәбез.<br>Туган җиремнең матурлыгы өчен ни кылдым? | булачак һәр нәрсәдән хәбәрдәр. | | яхшырак булуы ихтимал” (Хуҗурат, 11).<br>2. “Әй адәмнәр, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылыгыз һәм һичбер нәрсәне Аллаһы Тәгаләгә шәрик итеп тотмагыз. Ата-анагызга изгелек итегез. Янә якынлык иясе булган кардәшләрегезгә туганлык белән яхшылык итегез. Ятимнәргә шәфкать һәм мәрхәмәт белән, янә фәкыйрь һәм мескеннәргә садака бирү белән, янә якынлык иясе булган күршегә, янә кардәшлеге булмаган күршегә дә яхшылык итегез.<br>Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә тәкәбберлек кылучыларны һәм үз-үзен мактаучыларны сөймәс”. |
| | Мөселман кешесе бик | الجبار | 1. Л.Закирова “Нәрсә | “Юлдан җәяү барган кеше, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 28 атна<br>Һәр изгелек сәдакә | кечкенә булып тоелган яхшылык эшләүгә кимсенеп карарга тиеш түгел. Изгелекнең нинди генә зурлыкта булуына карамастан, аны эшләргә ашыгырга кирәк, зур изгелекме яки кечкенәме, сәдакә биргән кебек савап булачак. | Аллаһы Тәгалә үзенең хөкемен җиренә Җиткерүче, галәмнең тәртибе Ул куйган кануннар буенча барыр. | булган Рамилгә?” (Тәмле сүз, 52-53 бит).<br>Дәрдмәнд буенча “Гали” (Тәмле сүз, 50 бит). | юлда чәнечкеле агач ботагы күреп, аны алып атса, Аллаһ аны моның өчен мактар һәм гөнаһларын кичерер”.<br><br>“Һәр изгелек сәдакә”.<br><br>“Бер изге гамәлгә дә кимсенеп карамагыз, хәтта кардәшеңне ачык йөз белән каршы алуга да”.<br><br>“Ике кешене татулаштыру (ягъни ике талашкан кешене дуслаштыру) — сәдака, юлчы кешегә, мосафирга хайван өстенә менгәндә яки аның кирәк-ярагын куярга булышу – сәдака, яхшы сүз – сәдака, намазга юнәлгән һәр адым – сәдака, юлдан кешеләргә зарарлы нәрсәне алып кую сәдака”. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 29 атна<br>Исраф | Исраф – акча, мал һәм Аллаһ тарафыннан безгә бирелгән нигъмәтләрне сәбәпсез туздыру яки әрәм итүдер. Мәсәлән, кирәкле мәктәп әйберләрен артыгы белән куллану, ашауны күп итеп алып, ашамыйча калдыру, тәһәрәт алганда суны артык куллану, утны ихтыяҗ булмаганда яндыру, вакытны юкка уздыру һ.б. | **القابض**<br>Аллаһы Тәгалә теләгән вакытта колына биргән нигмәтләрен кире Алучы<br><br>**الباسط**<br>Аллаһы Тәгалә теләгән вакытта колына нигмәтләрен күп итеп Бирүче | “Балаларга иң кирәкле догалар” 47-50 бит. | “Эшләрнең хәерлесе – урта юлдыр”.<br><br>“Ике нигъмәт бар, кешеләрнең күбесе моны аңламыйча калалар. Беренчесе – саулык, икенчесе – буш вакыт”.<br><br>“Ашагыз, эчегез, ләкин исраф итмәгез, чөнки Аллаһ исраф кылучыларны сөймәс”. |
| 30 атна<br>Батырлык һәм куркаклык | Батырлык – кешенең катлаулы һәм куркыныч шартларда тәвәккәл, уйлап һәм кыю хәрәкәт итүе, үз хәрәкәтләрен контрольда тотуы, курку һәм каушау хисен җиңә алуы. Батырлык – кешенең якыннарын һәм үзен яклый алуы. Мәсәлән, Ватанын яклап, дошманга бирелмичә, тормышын | **القوى**<br><br>Аллаһы Тәгалә көчле, аның куәте җитмәс бер эш тә юк. | 1. “Балаларга иң кирәкле догалар” 57-59 бит.<br>2. “Маленький мусульманин” 58-64 стр.<br>3. М. Җәлил “Кызыл ромашка”. | “Батырлык – кешеләрне көрәшеп егуда түгел, бәлки ачу вакытында үзен тота белүдәдер”.<br>“Көчле мөэмин көчсез мөэмингә караганда Аллаһка сөеклерәктер, әмма икесендә дә хәер (яхшылык) бар. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | корбан иткән сугышчы батыр булып санала. | | | |
| 31 атна<br>Тәкәбберлек<br>һәм тыйнаклык | Тәкәбберлек – үзен башкалардан өстен күрү, үзен олылап, башкаларны түбән күрү дигән сүз. Тәкәбберлек ислам динендә хәрамдыр. Пәйгамбәребез гәләйһиссәләм һәрвакыт ихлас күңелле, тыйнак булган һәм безгә дә шундый булырга дип әйтеп калдырган. | المتكبر<br>Аллаһы Тәгалә олуглык, бөеклек, өстенлек һәм югарылык Иясе. | 1. “ Обувь” ( 40 хадисов в рассказах, 75-76 бит.).<br>2. “ Золото” (40 хадисов в рассказах, 35-36 бит.).<br>3. Карун кыйссасы<br>4. А. Алиш “Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык” (Тәмле сүз 76-77 бит). | “ Һәрбер диннең үзенең үзенчәлеге бар, Ислам диненең үзенчәлеге – тыйнаклык”.<br><br>“Әгәр кешенең күңелендә бер тамчы булса да тәкәбберлек бар икән, ул җәннәткә кермәс”.<br><br>“Тәкәбберләнгән кешене Аллаһ түбән төшерер, ихлас күңелле, тыйнак кешенең исә дәрәҗәсен күтәрер”. |
| 32 атна<br>Кибет, базар әдәбе | Кибеткә, базарга кергәндә укыла торган дога: “ Ләә иләһә илләЛлаһә уәхдәһә ләә шәрикә ләһү ләһүль мульку уә ләһүль хәмд, бийәәдихиль хайру уә һүә галә кулли шәййин кадир”. | الحكيم<br>Аллаһы Тәгалә хикмәт Иясе.<br>Һәр нәрсәне, һәрвакыт урынлы эшләр һәм эшләвенә | “Крепость маленького мусульманина”( 41-43 стр.). | “Базарга беренче кермәгез һәм ахыргы чыкмагыз, чөнки шайтан беренче үзенең байрагын куяр". |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кимчелек яки хата булмас. | | |
| 33 атна Авыруның хәлен белү | Авыруның хәлен белү бик саваплы. Кешенең авырып китүен белгәннән соң ук, туганнарыннан аның хәлен белешергә кирәк, чөнки Аллаһ бу эшне ярата. Авыру янына бару мөмкин булса, тизрәк янына бару саваплы санала. | **الشفاء**<br>Аллаһы Тәгалә шифа Бирүче | 1. “Витаминлы аш” ( Иң матур сүз, 216 бит).<br>2. “Агачлар да авырый” ( Иң матур сүз, 139 бит).<br>3. “Бал дәвалый” (Иң матур сүз, 146 бит). | 1. “Әгәр мөселман кардәшең авырып китсә, янына бар”.<br>2. “Авырган җиргә кулыгызны куеп, өч тапкыр: (“Аллаһ исеме белән”, - дип һәм җиде тапкыр: “Яманлыктан да, зарланулардан да Аллаһ Тәгаләнең көченә сыенамын”) дип, әйтегез дигән Мөхәммәд гәләйһиссәләм.<br>Авырудан саклану догасы:<br>**عن عائشة -رضي الله عنها- مرفوعاً: أن النبيَّ -صلى الله عليه وسلم- كانَ يَعُودُ بَعْضَ أَهْلِهِ يَمْسَحُ بِيدِهِ اليُمْنَى، ويقول: «اللَّهُمَّ رَبَّ النَّاسِ، أَذْهِب البَأسَ، اشْفِ أَنْتَ الشَّافِي لاَ شِفَاءَ إِلاَّ شِفاؤكَ، شِفَاءً لاَ يُغَادِرُ سَقماً«**<br><br>Транскрипция: Әллаһүммә Раббәннәәс, әзһибил-бәәс, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ишфиһи әнтәш-шәәфии, ләә шифәә,ә илләә шифәәүк, шифәә,ән ләә югадиру сәкамә.<br>Тәрҗемә: Әй Аллаһым-кешеләрнең Раббысы! Авыруны җибәр (бетер, ал), шифа бир Син бит шифа кылучы, Синең шифаңнан башка бүтән шифа юктыр, бу шифа һич бер авыруны да калдырмас. |
| 34 атна<br>Әмәнәт | Әмәнәт дип – саклану өчен кемгә дә булса тапшырылган нәрсәгә әйтәләр.<br>Безгә сер итеп сөйләнгән сүзләр дә әмәнәт. | **التواب**<br>Аллаһы Тәгалә тәүбәләрне кабул Итүче, гөнаһларны Кичерүче. | 1. “Маленький мусульманин”( 7- 10 бит.).<br>2. А. Алиш “Сертотмас үрдәк”. | “Сезгә бер әмәнәт калдырамын. Ул әмәнәтне саклагыз, туры юлдан адашмассыз. Бу әмәнәт – Аллаһның китабы – Коръән Кәримдер”.<br><br>“Берәр кеше сиңа нинди дә булса бер сүз сөйләгәндә, тирә-ягына карап сөйләсә, ул сүз – әмәнәттер. Ул сүзне башкаларга сөйләмә. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 35 атна<br>Кем ул тәрбияле бала?<br>Йомгаклау. | Бөтен өйрәнгән әдәпләрне кабатлау, ныгыту | **الواحد**<br>Аллаһы Тәгалә охшашы булмаган Зат. | 1. “ Спсобный мальчик” ( 40 хадисов в рассказах, 58-59 бит.).<br>2. Д.Аппакова “Рөстәм” ( Тәмле сүз, 24 бит). | “Яхшыгыз шул кеше – аннан изгелек көтелер, аның явызлыгыннан имин булыныр. Яманыгыз шул кеше – аннан изгелек тә көтелмәс, явызлыгыннан да имин булынмас”. |

# 7. КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Коръән Кәрим
2. Ислам дине нигезләре – Казан: “Хозур”- “Тынычлык” нәшрияте йорты, 2017. – 608 б.
3. Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларын ислам диненең рухи-әхлакый кыйммәтләре белән таныштыру программасы (төзүчеләр: К.В. Закирова, В.С.Казыйханов). – Казан: РИЦ “Школа”, 2006. – 32 б.
4. Җәлил хәзрәт дәресләре. Казан, 2012.
5. Максуди Әхмәдһади. Гыйбадәте исламия. – Казан: Идел-Пресс, 2013. – 112 бит.
6. “Әхлак дәресләре”. Укытучылар, сыйныф җитәкчеләре һәм тәрбиячеләр өчен дәрес эшкәртмәләре. Казыйханов В.С. “Яр Чаллы” нәшр. – 1998.
7. “Мәгърифәтче – галим, педагог Ризаэддин Фәхреддингә багышланган педагогик укулар программасы”. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, 2006.
8. Балаларга үгет-насыйхәт. Казан: “Дом печати” нәшрияты.- 2002. – 176б.
9. Көч һәм рух тамырлары: Әдәплелек дәресләре: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1998. – 223 б.
10. Мин динемне яратам / (төз.-авт. Г.Гайнетдинова). – Казан: “Идел-Пресс” типографиясы, 80б.
11. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011. – 560 б.
12. Иң матур сүз: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / (төз.-авт. К.В. Закирова). – Яңарт.3 нче басма. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015.- 431б.
13. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. Дәреслек. – Яр Чаллы: “Ислам нуры” эшмәкәрлек үзәге. - 2012. – 257б.
14. Тәмле сүз: әдәпле булу серләре / (төз. Талия Шакирова; рәссамы Алсу Тимергалина). – 2нче басма. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. – 79 б.: рәс. б-н.
15. Макарова Динә. Балаларга иң кирәкле догалар – дини тәрбияви хикәяләр, Казан: “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексы, 2013. – 80 б.
16. Макарова Дина. Маленький мусульманин, Нижнекамск: “Рисаля”, -2013.- 80стр.
17. Профессор М.Яшар Кандемир. 40 хадисов в рассказах. Перевод с турецкого. М.: ООО “Издательская группа “Сад”, 2009. 4-е издание. – 96 стр.
18. Прекрасные имена Аллаха. Поучительные истории. – СПб.: Издательство “Диля”, 2015. – 128стр.
19. Әхмәдһади Максуди “Мөгаллим сәни”. Казан: Хузур, 2015
20. Ислам дине нигезләре – Казан: “Хозур”- “Тынычлык” нәшрияте йорты, 2017. – 608 б.

21. Әхмәдһади  Максуди  “Гыйбадәте исламия”, - Казан:  Идел Пресс, 2013
22. Рашидә Исхакый “Намаз уку тәртибе”.
23. Ногмани тәфсире. Казан: ПИК “Идел-Пресс”, 2010.

**Балаларга**
**рухи-әхлакый тәрбия бирү**
**программасы**

Атнага бер көн йөрүче 3 - 7 яшьлек балалар өчен
(шимбә көн)

# 1. КӨНДӘЛЕК ТӘРТИП

8.00-8.15. Балаларны каршы алу.

8.15-8.30. Коръән уку, дога кылу.

8.30-8.50. Иртәнге чәй.

8.50-9.00 Тәнәфес.

9.00-9.30 Беренче шөгыль.

9.30-9.45. Тәнәфес.

9.45-10.15 Икенче шөгыль.

10.15-10.30 Тәнәфес.

10.30-11.00 Өченче шөгыль.

11.00-11.30 Төшке аш.

11.30-12.00 Тәһарәт алу, намаз уку.

12.00-12.30 Ирекле уеннар.

12.30-13.00 Өйләргә озату.

## 2. АҢЛАТМА ЯЗУЫ

**2.1. Программа түбәндәгеләргә нигезләнеп төзелгән**:

• "Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында" 26.09.1997 ел, №125-ФЗ Федераль закон һәм Татарстан Республикасы мөселманнарының Үзәк Дини оешмасы – Диния нәзарәте Уставы нигезендә, "Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында"гы Федераль закон.

• Бала хокуклары турында конвенция (13.12.1989 ел);

• Россия Федерациясе Гаилә Кодексы;

• СанПин 2.4.1.3079-13 СанПин мәктәпкәчә белем бирү санитар-эпидемиологик кагыйдәләре һәм нормативлары (Россия Юстиция министрлыгында 2014 елның 20 августында № 33660 теркәлгән).

• Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Балтач районы мөхтәсибәте Балтач Үзәк мәчете Уставының 2,3 бүлеге "е"бүлекчәсе.

• "Мәчет каршындагы курслар өчен дини тәрбия программасы" / төзүчеләр: Валиуллин Камил Хәмзә улы, Курамшин Ришат Исмәгыйл улы – Казан 2019.-103 б.

Балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирү – кешелек дөньясы алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе. Кешенең әхлагы булмаса, ул үзе дә, аның тирә-ягындагылары да бәхетсез була. Кызганычка каршы, бүгенге көндә бу проблема көн кадагына сугылган проблемаларның берсе. Җәмгыятебез социаль һәм икътисадый үзгәрешләр кичергән заманда, шәхеснең белемлелеге белән тәрбиялелеге арасында бәйләнеш өзелде кебек. Балаларның үз-үзләрен тотышларындагы тупаслыклар, кешеләр белән аралашуларындагы кимчелекләр һәммәбезне борчый. Мәгълүм ки, кешене яман эшләрдән белемлелек түгел, бәлки әхлак тәрбиясе, әдәплелеге, намуслылыгы саклый. Әхлак булганда гына тәрбияче көтелгән нәтиҗәләргә ирешә ала.

Белем һәм тәрбия бирү учрежденияләренең иң җаваплы, изге бурычы – балаларыбызны кечкенәдән инсафлы, әдәпле, мәрхәмәтле, белемле һәм сәламәт итеп тәрбияләү.

Әлеге программа дәүләт балалар бакчасына биш көн дәвамында йөрүче балалар өчен төзелде. Әлеге балалар физик, сөйләм, социаль-коммуникатив, танып-белү һәм иҗади эстетик үсеш буенча белемнәрне дәүләт балалар бакчасында алалар. Мәдрәсәбезгә килгәч, әлеге белемнәр әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, рухи-әхлакый кыйммәтләр, күркәм гадәтләр, әдәплелек күнекмәләре белән ныгытыла.

Бу программа атнага бер көн – шимбә көн йөрүче балалар өчен төзелгән. Бу уку көне, шимбә көн эштә булучы әти-әниләр өчен дә уңайлы, чөнки бу балалар мәдрәсәдә күзәтү астында булалар.

Шимбә көн мәдрәсәгә йөрүче балаларның күбесенең әти-әниләре дини гыйлемгә ия түгел. Бу үзенчәлек тә программа төзегәндә күз алдында тотып эшләнде.

Ризаэддин Фәхреддиннең зирәк сүзләрен яшь буынга тәрбия бирүдә девиз итеп алырга мөмкин: "Бала чакта алган тәрбияне соңрак бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас".

**Максатлар:**

- Балаларга дин турында башлангыч төшенчәләр бирү;
- Ислам диненең рухи-әхлакый кыйммәтләре белән таныштыру;
- Балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, үстерү;
- Татар халкының тәрбияви гореф-гадәтләре белән таныштыру.

**Бурычлар**:

1. Балаларда Ислам диненең кыйммәтләренә кызыксыну уяту, аларда динне белергә теләк, омтылыш үстерү;
2. Ислам дине кыйммәтләре нигезендә рухи-әхлакый сыйфатларны ныгыту, тәрбияләү;
3. Нәниләрнең уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү, дөньяны танып белү даирәсен киңәйтү;
4. Акыл эшчәнлеген, логик фикерләүне үстерү;
5. Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлылыкларын арттыру;
6. Сөйләм телләрен баету, фикерләрен нигезләп әйтә, сөйли белергә өйрәтү;
7. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша, балаларда Ватанга, туган якка, халыкка, туган телгә, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешеләргә карата мәхәббәт, ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү.

Программага темалар – киләчәк яшь буынны мәрхәмәтле, шәфкатьле, туган телен саклаучы һәм яратучы, гомум кешелекнең уңай сыйфатларына ия булган, милләт мәнфәгатен яклардай кеше итеп тәрбияләү бурычларын күз алдында тота.

### 2.2. Ислам кыйммәтләрен бирү аша балаларда түбәндәге рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләнә:

- Аллаһны тану һәм ярату. Ислам диненең нигезләрен, гадәтләрен саклау. Аллаһ Тәгалә йортлары – мәчетләрне ярату, ихтирам итү.

- Пәйгамбәребез гәләйһиссәләмнең тормышын өйрәнү. Аннан дәресләр, файдалар алу.

- Коръән Кәримгә мәхәббәт уяту, аңа карата хөрмәт тәрбияләү.

- Әти-әнигә карата мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү. Кушканнарын тыңлау. Гаиләнең кадерле булуын аңлату.

-Үз милләтеңне, Ватаныңны ярату. Үз милләтеңә, туган телеңә хөрмәт тәрбияләү. Милләтеңнең тарихын, мәдәни мирасын белү.

- Чисталык әдәпләрен бирү. Үзеңнең тәнеңне, киемеңне, бүлмәңне, йортыңны, әйләнә-тирә табигатьне чиста, пакь тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

- Сәламәтлекнең кадерен белү. Хәрамнан тыелу, хәләл ризык белән генә туклануны аңлату, белемнәрен баету.

### 2.3. 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларга әхлак тәрбиясе бирү программасы түбәндәге шөгылләрне үз эченә ала:

- **Гыйбадәт**

Балалар ике рәкагать намаз укыйлар һәм Коръән кабатлыйлар. Татарча матур итеп дога кылалар. Намаз эчендәге зекерләр, Аятел Көрси догасын кабатлыйлар, һәр атнаны бу догалар һәм сүрәләр кабатланып торганга, балалар исләрендә җиңел калдыралар. Намазны – өс киемнәре чиста, гаурәтләре капланган, малайлар түбәтәй, кызлар яулык киеп, Әбү Хәнифә мәзхәбе буенча укыйлар. Алдан тәһарәт тәртибен кабатлап, Азан әйтеп, Азан догасын кылалар.

- **Коръән ятлау**

Һәр атнаны балаларны кабул иткәч, түгәрәккә утырып, Коръән кабатлыйлар. Башта алда өйрәнелгән сүрәләр кабатлана, ә яңа сүрәне тәрбияче башта үзе берничә тапкыр укый, аннан балалар белән бергә кабатлый.

Көн дәвамында, шөгыльләр вакытында һәр бала үзе өйрәнеп килгән сүрәне сөйли. Сүрәне сөйләп тапшырган балага, икенче дәрескә өйрәнеп килер өчен яңа сүрә биреп җибәрелә.

Һәр ел ахырында районда Коръән, Намаз бәйгеләре үтә, аларда да балаларыбыз бүләкле урыннар алалар.

- **Әдәп-әхлак шөгыльләре**

Әхлак шөгылендә балага тема аңлатыла, темага кагылышлы берәр вакыйга яки әкият сөйләнелә. Шөгыль барышында, балаларга төрле сораулар бирелеп, җаваплар алына, әңгәмә төзеп тема ныгытыла. Көн дәвамында үткән материал әти-әнигә биреп җибәрелә.

Мәдрәсәдә шөгыльләр дәвамлылыгы якынча 30 минут.

# 3. ӘДӘП-ӘХЛАК

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Исәнләшү әдәбе. | 1 |
| 2 | Мәчет әдәбе. | 1 |
| 3 | Ашау әдәбе. | 1 |
| 4 | Юыну әдәбе. Чисталык. | 1 |
| 5 | Кием әдәбе. | 1 |
| 6 | Йокыдан тору һәм йокларга яту әдәбе. | 1 |
| 7 | Урамда йөрү әдәбе. | 1 |
| 8 | Әти-әнигә карата булган әдәп. | 1 |
| 9 | Йорт әдәбе. | 1 |
| 10 | Авыру кешенең хәлен белү. | 1 |
| 11 | Дөреслек-ялган. | 1 |
| 12 | Сабырлык. | 1 |
| 13 | Урлашу. Рөхсәтсез кеше әйберен алу. | 1 |
| 14 | Ярдәмләшү һәм юмартлык. | 1 |
| 15 | Шөкер кылу. | 1 |
| 16 | Тырышлык. | 1 |
| 17 | Яхшы һәм начар сүз. | 1 |
| 18 | Хайваннарга, үсемлекләргә, табигатькә карата әдәп. | 1 |
| 19 | Гаделлек. | 1 |
| 20 | Һәр изгелек сәдака. | 1 |
| 21 | Исраф. | 1 |
| 22 | Батырлык һәм куркаклык. | 1 |
| 23 | Туган җирне, туган телне ярату. | 1 |
| 24 | Тыйнаклык һәм мактану. | 1 |
| 25 | Дуслык, татулык. | 1 |
| 26 | Кем ул әдәпле һәм тәрбияле бала? | 1 |
| 27 | Исламда бәйрәмнәр. | 1 |
|  | Барлыгы | 27 |

# 4. ГЫЙБАДӘТ

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Тәһарәт – пакьлану чарасы. | 1 |
| 2 | Ислам диненең биш баганасы. Аның әһәмияте. | 1 |
| 3 | Намаз  шартлары. Тәкбир. Сәнә. | 1 |
| 4 | Тәкбир. Сәнә. | 1 |
| 5 | “Әгузү”. “Бисмилләһ”. | 1 |
| 6 | “Фәтихә” сүрәсе. | 1 |
| 7 | “Фәтихә” сүрәсенең өстенлеге. | 1 |
| 8 | “Кәүсәр” сүрәсе. | 1 |
| 9 | Рукугъ ( билдән бөгелү). | 1 |
| 10 | Рукугъ һәм сәҗдә зекерләре. | 1 |
| 11 | Әттәхият (Тәшәһһүд). | 1 |
| 12 | Әттәхият (Тәшәһһүд). | 1 |
| 13 | Салават. | 1 |
| 14 | Салават. | 1 |
| 15 | Раббәнә. | 1 |
| 16 | Раббәнә. | 1 |
| 17 | Сәлам догасы. | 1 |
| 18 | Сәлам догасы. | 1 |
| 19 | Аятел Көрси. | 1 |
| 20 | Аятел Көрси. | 1 |
| 21 | Аятел Көрси. | 1 |
| 22 | Азан догасы. | 1 |
| 23 | Азан догасы. | 1 |
| 24 | Азан догасы. | 1 |
| 25 | Азан догасы. | 1 |
| 26 | Кабатлау. | 1 |
| 27 | Үткән темаларны ныгыту. | 1 |
|  | Барлыгы | 27 |

## 5. ИМАН

| Дәрес | Эшчәнлекнең тематик эчтәлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Минем Раббым Аллаһ. | 1 |
| 2 | Аллаһ – бар итүче. | 1 |
| 3 | Аллаһ бу дөньяны һәм мәхлүкларны күркәм, матур һәм кимчелексез итеп бар иткән. | 1 |
| 4 | Аллаһ – пакь һәм пакьлыкны ярата. | 1 |
| 5 | Аллаһ Ризыкландыручы. | 1 |
| 6 | Аллаһны йокы да, йокымсырау да алмый. | 1 |
| 7 | Аллаһ – Саклаучы. | 1 |
| 8 | Аллаһ – Мәрхәмәтле. | 1 |
| 9 | Аллаһ – Күрүче. | 1 |
| 10 | Аллаһ – шифа Бирүче. | 1 |
| 11 | Аллаһ – Ишетүче. | 1 |
| 12 | Аллаһ сабыр һәм сабыр итүчеләрне ярата. | 1 |
| 13 | Аллаһ – яшерен һәм ачык әйберләрне белүче. | 1 |
| 14 | Ислам диненең беренче баганасы – шәһадәт кәлимәсе. | 1 |
| 15 | Ислам диненең икенче баганасы – намаз. | 1 |
| 16 | Ислам диненең өченче баганасы – ураза. | 1 |
| 17 | Ислам диненең дүртенче баганасы – зәкәт. | 1 |
| 18 | Ислам диненең бишенче баганасы – хаҗ. | 1 |
| 19 | Иман нигезләре – фәрештәләргә иман китерү. | 1 |
| 20 | Пәйгамбәрләргә иман китерү. | 1 |
| 21 | Пәйгамбәребез Мөхәммәд гәләйһиссәләм. | 1 |
| 22 | Китапларга иман китерү. | 1 |
| 23 | Коръән Кәрим. | 1 |
| 24 | Тәкъдиргә иман китерү. | 1 |
| 25 | Ахырзаман һәм Кыямәт көненә иман китерү. | 1 |
| 26 | Җәннәт. | 1 |
| 27 | Кабатлау. | 1 |
| | Барлыгы | 27 |

# 6. КӨНДӘЛЕК ҮТӘ ТОРГАН ҺӘМ ӨЙГӘ БИРЕП ҖИБӘРЕЛӘ ТОРГАН ДӘРЕСЛӘР ЭЧТӘЛЕГЕ

## Дәрес 1

### Әхлак

**Тема:** Исәнләшү әдәбе.

Мөселманнар бер-берсе белән очрашканда “**Әссәләму галәйкум уә рахмәтуллаһи уә бәракәтүһү”** дип елмаеп исәнләшә. (Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәракәте булсын дигәнне аңлата). Шушы сәламләүне ишеткән кеше исә “**Үә галәйкумүссәләм үә рахмәтуллаһи уә бәракәтүһү”** дип җавап кайтара.

Г.Садә “Әссәләму галәйкум”, В.Хәйруллина “Хәерле көн” ( “Иң матур сүз” китабыннан)

### Гыйбадәт

**Тема:** Тәһарат – пакьлану чарасы.

Тәһарәт алу тәртибе:

- Бәдрәфкә кереп истинҗә кылу;
- Кулларны 3 мәртәбә юу;
- Авызны 3 мәртәбә чәйкау;
- Борынны 3 мәртәбә юу;
- Битне 3 мәртәбә юу;
- Беләкләрне терсәккә кадәр 3 мәртәбә юу;
- Башка мәсех (колак һәм муен да кереп) кылу (юеш кул белән сыпыру);
- Уң аякны, аннары сул аякны тубыкларга кадәр 3 мәртәбә юу.

### Иман

**Тема:** Минем Раббым Аллаһ.

Аллаһ – җирне һәм күкләрне, барлык галәмнәрне барлыкка китерүче.

Аллаһ – кешене, барлык тере һәм тере булмаган нәрсәләрне юктан бар итүче.

Аллаһ - бердәнбер Илаһ, ягъни гыйбадәткә лаеклы бердәнбер Илаһи Зат. Аннан башка беркемгә дә, бернәрсәгә дә гыйбәдәт кылырга ярамый.

## Дәрес 2

### Әхлак

**Тема:** Мәчет әдәбе.

Мәчетләребез Аллаһы Тәгалә хөрмәтләгән йортлар.

1. Мәчеткә керер алдыннан тәннең һәм киемнең чиста булуына, үзеңнән начар ис килмәвенә ышанган булырга тиеш.

2. Аяк киемен салып керергә кирәк.

3. Мәчеткә уң аяк белән атлап керәбез һәм шушы доганы укыйбыз: “**Аллаһүммә-фтәхли әбүәбә рахмәтик”** (Я, Раббым, миңа рәхмәт ишекләреңне ач).

4. Мәчеттән чыкканда сул аяк белән чыгабыз: **“Аллаһуммә фтәхли әбүәбә фадлик”** (Йә, Раббым, миңа дөнья нигъмәтләрен ач) дип, дога әйтәбез.

В.Хәйруллина “Азан әйтә бер малай” (“Иң матур сүз” китабыннан).

### Гыйбадәт

**Тема:** Ислам диненең 5 баганасы. Аның әһәмияте. Тәһарәт.

Тәһәрәт алу тәртибе:

- Бәдрәфкә кереп истинҗә кылу.
- Кулларны 3 мәртәбә юу.
- Авызны 3 мәртәбә чайкау.
- Борынны 3 мәртәбә юу.
- Битне 3 мәртәбә юу.
- Беләкләрне терсәккә кадәр 3 мәртәбә юу;
- Башка мәсех (колак һәм муен да кереп) кылу (юеш кул белән сыпыру).
- Уң аякны аннары сул аякны тубыкларга кадәр 3 мәртәбә юу.

**Иман**

**Тема:** Аллаһ – бар итүче.

Кояш безгә Аллаһ кушуы белән үз җылысын һәм яктысын бирә. Төннәрен безгә яктылык бирүче ай һәм йолдызларны төзелеше, көн-төн алмашынуы, җәйләрнең эссе булуы, көзләрнең яңгырлы һәм суык булуы, язларда кояшның якыннан җылытып карларны эретүе һәм агачларда бөреләрнең яфракка әйләнүе, кыш аенда кар һәм бураннар булуы, җирләргә туң төшүен - боларның барысы белән дә кем идарә итә соң? Әлбәттә, болар барысы да Аллаһның кушуы белән эшләнелә. Судагы балыклар, җирдәге кыргый хайваннар һәм кешеләрнең ризыгы һәм язмышы барысыда Аллаһ кодрәте белән төзелгән.

**Дәрес 3**.

**Әхлак**

**Тема:** Ашау әдәбе.

Ашар алдыннан кулларны юу. Олылардан алда өстәл янына утырмау. Ашарга утыргач “БисмиЛләһ” дип, үз алдыңнан гына түкми, чәчми, әдәп белән генә ашау. Туенганнан соң артыгын ашамау, Аллаһ Тәгаләгә шөкер итәбез һәм түбәндәге доганы укыйбыз: **“Әлхәмдү-лил-Ләәһил-ләзии, этгамәнәә үә сәканәә үә җәгәләнәә минәл-мүслимиин"** һәм эти-әниеңә рәхмәт әйт. Кулларны юу, авызны чайкау.

Б.Рахмәт “Аш вакыты” ( “Иң матур сүз” китабыннан). “Балаларга иң кирәкле догалар” 3-5 б.

**Гыйбадәт**

**Тема:** Намаз шартлары.

1. Намаз уку урыны, киемнәрнең һәм тәннең чиста булуы.
2. Гаурәт каплануы.
3. Намаз вакыты керүе.
4. Кыйблага йөз белән юнәлү.
5. Ният кылу.

**Тема:** Тәкбир. “Сәнә”.

**“Сүбехәәнәкә Аллаһүммә үә бихәмдикә, үә тәбәәракә-смүкә үә тәгәәлә җәддүкә, үә ләә иләәһә гайрук”.**

**Иман**

**Тема:** Аллаһ бу дөньяны һәм мәхлүкларны күркәм, матур һәм кимчелексез итеп бар иткән.

Аллаһ Тәгалә кешеләрне һәм хайваннарны, кошларны һәм үсемлекләрне, елгаларны, күлләрне, кояшны, айны, йолдызларны, җирне һәм күкне күркәм, матур, камил иткән.

## Дәрес 4.

**Әхлак**

**Тема:** Юыну әдәбе, чисталык.

Ислам динендә чисталык зур урын алып тора. Мөхәммәд гәләйһиссәләм әйткән: “Чисталык – ярты иман”. Ислам дине чисталыкка, мөселман кешесенең тышкы һәм эчке сафлыгына һәрвакыт игътибарлы булган. Шәхси гигиена мәсьәләсе дә мөселманнар өчен бик әһәмиятле. Аның шундый зур мәгънәгә ия булуы гыйбадәт үзенчәлекләреннән килә.

Бәдрәфкә кергәндә сул аяк белән “**БисмиЛләһи, Аллаһүммә инни әгузу бикә минәл хубси уәл-хәбәис**” дигән доганы әйтеп керү кирәк. Йомышны үтәгәч уң аяк белән атлап чыгып, “**Гуфранәк**” дип әйтү, чыккач юыну.

“Балаларга иң кирәкле догалар” 42-44 б.

**Гыйбадәт**

**Тема:** Тәкбир. Сәнә.

**“Сүбехәәнәкә Аллаһүммә үә бихәмдикә, үә тәбәәракә-смүкә үә тәгәәләә җәддүкә, үә ләә иләәһә гайрук”.**

**Иман**

**Тема:** Аллаһ пакь, һәм пакьлыкны ярата.

“Дөреслктә, Аллаһ тәүбә итүчеләрне һәм үз-үзен һәм күңел, тән нәҗесләреннән пакьланучыларны сөядер”.(хәдис)

“Чисталык – ул  ярты иман” (хәдис). Йорт тирәсен, яшәү мөһитен чистарту  һәрберебезнең бурычы булып тора.

## Дәрес 5

### Әхлак

**Тема:** Кием  әдәбе.

Киемнәрегезне саклап киегез, өс-башыгызның тәртипсез булуы ялкаулык һәм пычраклык галәмәтедер. Күркәм сыйфатта күренегез. Киемнәрегез чиста, пөхтә булсын!

### Гыйбадәт

**Тема: «** Әгүзү», «Бисмилләһ».

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтанир-ражиим.

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахииим.

### Иман

**Тема:**  Аллаһ – Ризыкландыручы.

Аллаһ Тәгалә үзенең бар кылган мәхлүкларын, җан ияләрен, кешеләрне һәм хайваннарны ризыкландырып тора. Бар нигъмәт Аллаһ Тәгаләдән икәнен балаларга төшендерү.

## Дәрес 6.

### Әхлак

**Тема:** Йокыдан тору һәм йокларга яту әдәбе.

Йокларга ятыр алдыннан тешләрне яхшылап юып, киемнәрне урынына элеп, тәһарәт алып яту күркәм санала, чөнки тәһәрәтсез кеше начар төшләр белән саташырга мөмкин. Йокларга ятканда үзенең укыла торган догасы бар: **“Бисмикә Аллаһүммә әмүтү уә әхъя”.** (Тәрҗемәсе: “Аллаһым, Синең исемең белән үләм һәм тереләм”). Аннан соң уң якка борылып, **Әгүзү, Бисмилләһ**не әйтеп, әти-әнигә “Хәерле төннәр” теләп, йокларга ятабыз. Һәр

көн билгеләнгән вакытта йокларга яту яхшы.

Иртә белән **бисмилләһ**не әйтеп уң аяк белән басабыз. Уянгач укыла торган доганы укысаң, көнең уңышлы, бәракәтле үтәр: **“Әлхәмдү лилләһил-ләзий әхъянәә бәгъдә мә әмәәтәнәә уә иләйһин-нушуур”.** Шушы доганы укыгач, тешләрне юып, чиста киемнәрне киябез.

“Балаларга иң кирәкле догалар” 6-11 бит.

## Гыйбадәт

**Тема:** “Фәтихә” сүрәсе.

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтанир-ражиим.

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахииим

**1. Әл-хәмдү лилләәһи Раббил гааләмииииин.**

**2. Әр-рахмәәнир-рахииим.**

**3. Мәәлики йәүмид-дииин.**

**4. Иийййәәкә нәгъбүдү үә иийййәәкә нәстәгыйииин.**

**5. Иһдинәс-сыйраатаһль-мусьтәкыйииим.**

**6. Сыйрааталь-ләзиинә әнгамтә галәйһим, гайрил-мәгъдууби галәйһим үәләд-даааааллииин. Әмииин.**

## Иман

**Тема:** Аллаһны йокы да, йокымсырау да алмый.

Йокы һәм йокымсырау, ял итү Аллаһка карата зур кимчелектер. Ибн Гәббәс әйтте: “Бер вакыт Бәнү Исраил кавеме Муса(г.с)нән Аллаһ йоклыймы дип сорадылар. Бу сорауны Муса(гс) Аллаһка әйтте һәм Аллаһ әйтте: “Ике кулыңа ике чүлмәк ал да, төне буе шуларны тотып тор”. Төннең өченче өлешендә Муса(гс) йокымсорап китте һәм кулындагы савытлар төшеп ватылды. Аллаһ әйтте: “Әгәр дә Мин йокласам, җир һәм күкләр шушы чүлмәкләр кебек юк булачак”.

## Дәрес 7

### Әхлак

**Тема:** Урамда йөрү әдәбе.

Урамга чыкканда әти-әнидән рөхсәт алып чыгарга. Үз-үзеңне тәртипле, әдәпле, тыйнак тотарга кирәк. Берәр транспортка утыргач укыла торган дога: **“Сүбхәәнә-лләзии сәххара ләнәә һәәзә уә мәә күннәә ләһүү мүкъриниин. Үә иннә иләә раббинәә ләмүңкалибүүн”.**

Мәгънәсе: “Бу нәрсәләрдән (ат, дөя, машина) безне файдаландыручы Аллаһ Тәгалә һәр кимчелектән пакътер. Әлбәттә, бу нәрсәләрне без үзебез булдыра алмас идек. Һәм без, әлбәттә, Раббыбызга әйләнеп кайтачакбыз”.

### Гыйбадәт

**Тема:** “Фәтихә” сүрәсенең өстенлеге.

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим.

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахииим.

**1. Әл-хәмдү лилләһи Раббил гааләмиииин.**

**2. Әр-Рахмәәнир-Рахииим.**

**3. Мәәлики йәүмид-дииин.**

**4. Ииййәәкә нәгъбүдү үә ииййәәкә нәстәгыйииин.**

**5. Иһдинәс-сыйрааталь-мусьтәкыйииим.**

**6. Сыйрааталь-ләзиинә әнгамтә галәйһим, гайрил-мәгъдууби галәйһим үәләд-дааааллииин. Әәмииин.**

### Иман

**Тема:** Аллаһ — Саклаучы.

Аллаһ Тәгалә җирне, күкләрне, бөтен галәмне, кояшны, айны, планеталарны саклый. Алар бер-берсенә бәрелмиләр. Аллаһ Тәгалә безне төрле бәлә-казалардан, начарлыклардан саклый. Һәрбер кешене саклау өчен фәрештә билгеләнгән.

## Дәрес 8

### Әхлак

**Тема:** Әти-әнигә карата булган әдәп.

Сезгә иң якын кешеләр әти-әниләрегез. Шуның өчен аларга һәрвакыт итәгатьле булыгыз, эштә һәм сүздә аларга каршы килмәгез, алар алдында әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тотыгыз. Аллаһ Тәгалә Коръәндә әти-әнигә яхшылык кылырга кушты: **“Әгәр аларның берсе яки икесе дә синең янында картлыкка ирешсәләр, син аларга “Уф” дип тә әйтмә, аларга кычкырма, ә яхшы, мөлаем сүзләр генә сөйлә”.**

### Гыйбадәт

**Тема: “**Кәүсәр” сүрәсе.

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахииим.

**1. Иннә әгътайнәә кәл-кәүсәр.**

**2. Фәсалли лираббикә үәнхәр.**

**3. Иннә шәәни-әкә һүүвәл-әбетәр.**

### Иман

**Тема:** Аллаһ – Мәрхәмәтле.

Мөселман каты йөрәкле, каты күңелле түгел, киресенчә, мәрхәмәтле һәм йомшак күңелле була. Мәрхәмәтлелек – ул барлык яхшы эшләр, елмаюлы караш, кемгә дә булса булышу, ярдәм итү, хөрмәт һәм ихтирам дигәнне аңлата. Аллаһның рәхмәте һәм мәрхәмәте чиксездер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд(сгв) бер хәдисендә әйткән: “Аллаһ Тәгәлә рәхмәт һәм мәрхәмәтен йөз өлешкә аерды, шуның бер өлешен генә җиргә, кешеләр һәм хайваннар арасына төшерде. Менә бу бер өлеш мәрхәмәт аркылы кешеләр бер-берләренә мәрхәмәтле, хәтта хайван да үзенең балаларына йомшактыр. Ләкин туксан тугыз өлешен үзе янында калдырды, кыямәт көнендә изге бәндәләренә бирү өчен”.

## Дәрес 9

### Әхлак

**Тема:** Йорт әдәбе.

Йортлар безне салкыннан, кызудан, яңгырдан, кардан саклый. Без өйләребездә ял итәбез, ашыйбыз, эчәбез, дусларны кунакка чакырабыз.

**Өйгә кергәндә укыла торган дога:**

**“Бисмилләәһи үәләҗнәә үә бисмиЛләәһи хараҗнәә вә галәЛлааһи раббинәә тәүәккәлнәә."**

(Аллаһының исеме белән кердек, Аллаһының исеме белән чыктык. Раббыбыз Аллаһка тәвәкәлләдек.)

**Өйдән чыкканда укыла торган дога:**

**"Бисмилләәһ. Тәүәккәлтү галәЛлааһ. Үә ләә хәүлә үә ләә куүәтә илләә биЛләәһ".**

(Аллаһ исеме белән. Аллаһка тәвәккәл иттем. Аллаһтан башка көч тә куәт тә юк).

“Балаларга иң кирәкле догалар” 31-35 б.

### Гыйбадәт

**Тема:** Рукугъ (билдән бөгелү).

“**Аллаһу әкбәр**”дип әйтеп рукугъка китәбез.

Рукугъда укыла торган зекер:

“**Сүбеханә раббиәль-газыйм**” (3 тапкыр)

Шуннан соң “**СәмигаЛлаһу лимән хәмидәһ**” дип тураеп басабыз.

### Иман

**Тема:** Аллаһ – Күрүче.

Аллаһ Тәгалә бар нәрсәне күреп тора. Аңардан бер әйберне дә яшереп булмый. Ул хәтта караңгы төнне таш астында хәрәкәтләнүче кырмысканы да күрә. Аллаһ бар нәрсәне Күрүче һәм Белүче.

## Дәрес 10

### Әхлак

**Тема:** Авыру кешенең хәлен белү.

Туганнарыгызның, дусларыгызның авырганнарын ишетсәгез, хәлләрен белергә барыгыз. Яннарына керү мөмкин булмаса, хәлен өйдә булганнардан сорагыз. Авыручының күңелен юатыгыз, сабырлыкка чакырыгыз, сәламәтлеге өчен дога кылыгыз.

Авыру кеше өчен түбәндәге доганы укыйбыз: **“Лә бәъсә таһүрун иншәАллаһ”.**

Хәдис: “Мөселманның икенче мөселман алдында 5 хакы бар: сәламгә җавап бирү, авыручының хәлен белү, соңгы юлга озату, чакыруны кабул итү һәм төчкерүчегә “йәрхәмүкәЛлаһ” дип әйтү.”

“Витаминлы аш”, “Агачлар да авырый”, “Бал дәвалый” (“Иң матур сүз” китабыннан).

### Гыйбадәт

**Тема:** Рукугъ (билдән бөгелү) һәм сәҗдә зекерләре.

**“Аллаһу әкбәр”** дип әйтеп рөкугъка китәбез.

Рукугъда укыла торган зекер: **“Сүбеханә раббиль-газыйм”** (3 тапкыр)

Шуннан соң **“СәмигаЛлаһу лимән хәмидәһ”** дип тураеп басабыз. Тураеп баскач, **“Раббәнәә вә ләкәл-хәмде**” дип әйтәбез һәм **“Аллаһу әкбәр”** дип сәҗдәгә китәбез. Сәҗдәдә 3 тапкыр **“Сүбхәәнә Раббииль-әгълә”** дип әйтәбез. Сәҗдә ике тапкыр кабатлана.

### Иман

**Тема:** Аллаһ шифа Бирүче.

Һәрбер авыруга шифаны бары тик Аллаһ кына бирә. Без сәбәбен кылабыз, дарулар эчәбез, табибка барабыз, ә нәтиҗәне Аллаһтан өмет итәбез.

## Дәрес 11

### Әхлак

**Тема:** Дөреслек-ялган.

Мөселман барлык кешеләр белән дә гадел була. Ул яхшылыкның

нигезендә дөреслек ятканын белә. Шул дөреслек аңа юл күрсәтә, аны җәннәткә илтә. Ялган сөйләү – динебездә зур гөнаһларның берсе. Тормышыбыздагы бик күп күңелсез хәлләр ялган ярдәмендә килеп чыга. “Әй, мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз! Сөйләгән вакытта чын дөресен сөйләгез” (Коръән).

Ялганчы кеше, башкаларны алдаса да, Аллаһны алдый алмас, чөнки Аллаһ һәрнәрсәне күрә, сөйләгән һәрбер сүзләрне ишетеп тора.

Алиш А. “Алдакчы Наил”, “Дөресен сөйләү җиңел” (“Пәйгамбәрләр тормышы үрәгендә” китабыннан).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Әттәхият (Тәшәһһүд).

“**Әттәхиятү лилләәһи вәссаләвәәту вәттайбәәт. Әссәләму галәйкә әййүһән-нәбийу вә рәхмәтуллааһи вә бәракәәтүһ. Әссәләму галәйнәә вә галәә гыйбәәдил ләәхис саалихиин. Әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вә әшһәдү әннә Мухәммәдән габедүһүү вә расүүлүһ”.**

**Иман**

**Тема:** Аллаһ – Ишетүче.

Аллаһ Тәгалә бар нәрсәне ишетеп тора. Аңардан бер әйберне дә яшереп булмый. Ул тавыш кайдан гына килсә дә, нинди генә әкрен яки каты булса да Аллаһ аларны ишетә. Аллаһ хәтта безнең әйткән сүзләрне генә түгел, ә уйлаган уйларыбызны да белеп тора. Аллаһның ишетүендә бернинди дә чикләр юк.

## <u>Дәрес 12</u>

**Әхлак**

**Тема:** Сабырлык.

Сабырлык ул - Аллаһы Тәгалә биргән зур нигъмәт. Сабырлык - түземле булу, авыр хәлләр килгәндә чыдам булып, үзеңә хуҗа булу, ямьсез сүзләр һәм начар хәрәкәтләрдән тыела белүдер. Сабырлык - иманның яртысы.

**Сабырлык өч төрле була:**

1. Бәла-казаларга карата булган сабырлык. Зилзилә, су басулар, сугышлар кебек хәлләрдә авырлыкларга чыдап, сабыр итәргә кирәк.

2. Гыйбадәтләрне сабырлык белән кылу.

3. Гөнаһ эшләрне кылмауда сабырлык итү.

“Сабырлык – җәннәт ачкычы” (“Пәйгамбәрләр тормышы үрәгендә” китабыннан).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Әттәхийәт.

“**Әттәхиятү лилләәһи вәссаләвәәту вәттайбәәт. Әссәләму галәйкә әййүһән-нәбийу вә рәхмәтуллааһи вә бәракәәтүһ. Әссәләму галәйнәә вә галәә гыйбәәдил ләәхис саалихиин. Әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вә әшһәдү әннә Мухәммәдән габедүһүү вә расүүлүһ”.**

**Иман**

**Тема:** Аллаһ сабыр һәм сабыр итүчеләрне ярата.

Пәйгамбәребез (сгв) болай дигән:

“Көрәштә иптәшләрен җиңгән кеше түгел, ә бәлки, нык ачуланган хәлдә, сабыр итеп, үз ачуын җиңгән кеше генә көчле кеше санала”.

**<u>Дәрес 13</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Урлашу. Рөхсәтсез кеше әйберен алу.

Урлау – башкаларның малын рөхсәтсез, яшерен рәвештә алу, үзләштерү. Бу бик зур гөнаһларның берсе. Ләкин күңелендә иманы булган кеше Аллаһтан куркып, бу начар эшне эшләмәс, чөнки Аллаһ бар нәрсәне Күрүче һәм Белүче.

“Чит кеше чиясе” (“Балаларга иң кирәкле догалар”).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Салават.

**“Әллааһүммә салли галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә гәләә Ибрааһиимә үә гәләә әәли Ибрааһиимә иннәкә**

**хәмиидүм мәҗииide.**

**Әллааһүммә бәәрик галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә гәләә Ибрааһиимә үә гәләә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм мәҗииide".**

**Иман**

**Тема:** Аллаһ – яшерен һәм ачык әйберләрне Белүче.

Аллаһ барлык әйберне Белүче, Күрүче һәм Ишетүче: булганын да, булачагын да, яшеренне һәм ачыкны. Җирдә, диңгездә булган әйберләрне Белүче, Аллаһ теләгеннән башка бер генә яфрак та селкенми, аның ризалыгы булмыйча без бер генә сулыш та ала алмыйбыз.

**<u>Дәрес 14</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Ярдәмләшү һәм юмартлык.

Юмартлык – ул үзенә нинди дә булса файда килүне өмет итмичә кешеләргә ярдәм итү. Кешеләр арасында көчлеләр дә, зәгыйфьләр дә, байлар һәм ярлылар да, галим һәм белемсезләр дә бар. Һәрбер кеше, кем булуына карамастан, бер үзе генә яши алмый. Ул башка кешеләрнең ярдәменә мохтаҗ. Шул сәбәпле, динебез үзара ярдәмләшүне һәм юмартлыкны фарыз кылган.

Ишморатова Р. "Яңа чана" ("Көч һәм рух тамырлары" китабыннан).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Салават.

**"Әллааһүммә салли галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә гәләә Ибрааһиимә үә гәләә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм мәҗииide.**

**Әллааһүммә бәәрик галәә Мүхәммәдин үә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә гәләә Ибрааһиимә үә гәләә әәли Ибрааһиимә иннәкә хәмиидүм мәҗииide".**

**Иман**

**Тема:** Ислам диненең беренче баганасы – шәһадәт кәлимәсе.

Шәһадәт кәлимәсе: **Әшһәдү әллә Иләһә иллә Аллаһ вә әшһәдү әннә Мухәммәдәр Расүлүллаһ.**

Иман кәлимәсе: **Лә Иләһә иллә Аллаһ Мухәммәд Расүлүллаһ –** Аллаһы Тәгаләдән башка иләһ юк һәм Мөхәммәд гәләйһиссәләм Аның Рәсүле, дигәнне аңлата. Аллаһ Тәгалә: "Шуны бел: Аллаһтан башка иләһ юк", - диде. Мөхәммәд гәләйһиссәләм: "Аллаһы Тәгаләдән башка иләһ юк" дип әйткән кеше җәннәткә керәчәк", - диде.

"Автомобиль" ( из книги "40 хадисов в рассказах").

## Дәрес 15

### Әхлак

**Тема:** Шөкер кылу.

Аллаһы Тәгалә кешеләргә санаусыз нигъмәтләр биргән: акыл, гәүдәбезгә көч-куәт, саулык, ашау-эчүләребез һәм башка чиксез нигъмәтләр. Шулай ук, табигатьтәге һәрнәрсәне: һаваны, суны, җиләк-җимешләрне, үсемлекләрне, хайваннарны да бар итүче – Аллаһы Тәгаләдер. Кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылырга һәм бу нигъмәтләрнең чын хуҗасын һәрвакыт олылап искә алырга тиеш.

### Гыйбадәт

**Тема:** Раббәнә.

**"Раббәнәәә әәтинәә фид-дүньйәә хәсәнәтәү - үә филь әәхирати хәсәнәтәү-үә кыйнәә гәзәәбән-нәр".**

### Иман

**Тема:** Ислам диненең икенче баганасы – намаз.

Аллаһ Тәгалә: "Намаз кешеләрне начар гамәлләрдән тыяр", - ди. "Намазның ачкычы – тәһарәт, ә җәннәт ачкычы – намаз", – диде Мөхәммәд гәләйһиссәләм. Мөселман кешесе көнгә биш вакыт намаз укый. Намаз тәһарәт белән укыла. Намаз – күңелдән Аллаһ белән сөйләшү дигән сүз.

## Дәрес 16

### Әхлак

**Тема:** Тырышлык.

Мөселман кешесе – дөнья һәм Ахирәт эшләрен тигез алып бара. Дөньяда да, Ахирәттә дә бәхетле яшәү – мөселманның хакы. Дөньяда бәхетле булыр өчен, Ахирәтне онытмыйча, тырышлык белән яшәргә кирәк, чөнки дөнья тормышы безгә вакытлыча бирелгән, ул бик тиз үтеп китәчәк. Ахирәт тормышы гына мәңгедер.

Тукай Г. "Эш беткәч уйнарга ярый", "Кызыклы шәкерт".

### Гыйбадәт

**Тема:** Раббәнә.

**"Раббәнәәә әәтинәә фид-дүньйәә хәсәнәтәү- үә филь әәхирати хәсәнәтәү-үә кыйнәә гәзәәбән-нәр".**

### Иман

**Тема:** Исламның өченче баганасы – ураза.

Хәдис: "Рамазан ае – ул мөбәрәк ай. Ул айда җәннәт капкалары ачыла, тәмүгъ капкалары ябыла. Анда бер кичә бар, ул мең айдан да хәерлерәк."

## Дәрес 17

### Әхлак

**Тема:** Яхшы һәм начар сүз.

Яхшы сүз – ул яхшылыкка чакыру һәм начарлыктан ераклаштыручы һәр сүз ул. Аңа Аллаһы Тәгаләне зекер кылу, сәлам бирү, аралары бозылган ике кешене дуслаштыру һ.б. керә. Ислам дине безне яхшы сүзләр сөйләргә чакыра, чөнки ул кешеләр арасында мәхәббәтне арттыра.

Начар сүз исә – ул начарлыкка өндәүче һәм яхшылыктан ераклаштыручы һәр сүз. Аңа гөнаһ эшләргә чакыру, начар сүз сөйләү, кешене мыскыл итү, ялганлау һ.б. керә.

### Гыйбадәт

**Тема:** Сәлам догасы.

**"Аллаһуммә әнтәс-сәләәму вә минкәс-сәләәм, тәбәәрактә йәә зәл-җәләәли үәл-икрам".**

**Иман**

**Тема:** Исламның дүртенче баганасы – зәкәт.

Зәкәт байлар тарафыннан мескеннәргә һәм мохтаҗларга бирелә. Зәкәт малы акчадан, хайваннардан бирелергә мөмкин. Зәкәт – Аллаһ Тәгалә тарафыннан фарыз итеп куелган гамәл.

**<u>Дәрес 18</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Хайваннарга, үсемлекләргә, табигатькә карата әдәп.

Бу дөньяны һәм мәхлүкларны кем бар иткән? Аллаһы Тәгалә кешеләрне, хайваннарны һәм кошларны, үсемлекләрне, елгаларны, күлләрне, кояшны, айны, күк йөзен һәм бар әйберне юктан бар итте. Аллаһ безгә аларны сакларга һәм рәнҗетмәскә кушты.

"Агачлар да авырый" ( "Балачак аланы" китабыннан ).

"Барлык мәхлук (табигать) Аллаһның гаиләседер, Аллаһка иң сөекле булган кеше, Аның мәхлүкларына (табигатькә) файдалы булганыдыр" хәдис.

**Гыйбадәт**

**Тема:** Сәлам догасы.

**"Аллаһуммә әнтәс-сәләәму вә минкәс-сәләәм, тәбәәрактә йәә зәл-җәләәли үәл-икрам".**

**Иман**

**Тема:** Исламның бишенче баганасы – хаҗ.

Ислам дине нигезләренең бишенчесе – кешегә гомерендә бер мәртәбә Мәккә шәһәренә барып хаҗ кылу. Хаҗы дөрес һәм тулы булсын өчен, ул, хаҗга барыр алдыннан, аның барлык тәртипләрен дә җентекләп өйрәнә, кешеләргә булган бурычларын үти, хаталары өчен гафу үтенә, араларны төзәтә. Хаҗ кылып өенә, гаиләсе янына әйләнеп кайтканда, гөнаһларыннан чистарынып, үзен яңа туган бала кебек хис итә.

## Дәрес 19

### Әхлак

**Тема:** Гаделлек.

Гаделлек – хак һәм дөреслекне сөйләү, явызлыкны калдыру, эшләребездә, гамәлләребездә, сүзләребездә дөрес булу дигәнне аңлата. Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтә: “Аллаһ Тәгалә гадел булырга, изге эшләрне эшләргә, ярлы кардәшләрегезгә ярдәм итәргә куша һәм сезне начар, ямьсез эшләрдән, кешеләргә золым кылудан тыя”.

“Пастух и его старые родители” ( из книги “Маленький мусульманин”).

### Гыйбадәт

**Тема:** Аятел Көрси.

**“Әллааху ләәәә иләәһә иллә һувәль Хәййүль Каййуум. Ләә тәъхузуһүү синәту-вә-ләә нәуум. Ләһү мәә фис сәмәәвәәти вә мәә филь ард. Мән зәльләзии йәшфәгу, гиндәһү иллә би-изниһ. Ягләму мәә бәйнә әйдииһим вә мәә хальфәһум, вә ләә йухиитуунә бишәйим-мин гильмиһии илләә бимәә шәәәә. Вәсига курсиййухус сәмәәвәәти вәль ард. Вә ләә йәъудуһүү хифзуһумәә вә һуәль галийуль газыйм”.**

### Иман

**Тема:** Иман нигезләре – фәрештәләргә иман китерү.

Фәрештәләр Аллаһы Тәгаләнең бик итәгатьле коллары. Алар нурдан яратылган. Аллаһы Тәгаләгә һәрвакыт гыйбадәт итәләр, Аңа мактау һәм тәсбих әйтеп торалар. Аллаһ Тәгалә аларга нәрсә кушса, шуңа һич каршы килмичә, аны җиренә җиткереп башкаралар. Алар һич гөнаһлы эшләрне эшләмиләр.

## Дәрес 20

### Әхлак

**Тема:** Һәр изгелек сәдака.

Ислам дине буенча кеше башкаларга файда гына китерергә, ә зыян китерергә мөмкин булган һәрнәрсәдән үзен сакларга тырыша. Мөхәммәд сгв әйткән: “Әгәр ачуланышкан ике кешене дуслаштырсаң, бу эшең сиңа сәдака

булыр, әгәр кешегә атланып утырырга  яки йөген куярга ярдәм итсәң, бу эшең дә сәдака булыр. Һәр яхшы сүз сәдака”.

Нуриев Г. “Урман суы төшкәндә” (“Тәмле сүз” китабыннан”).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Аятел Көрси.

**“Әллаахy ләәәә иләәhә иллә hувәль Хәййүль Каййуум. Ләә тәъхузуhүү синәту-вә-ләә нәуум. Ләhү мәә фис сәмәәвәәти вә мәә филь ард. Мән зәльләзии йәшфәгу, гиндәhү иллә би-изниh. Ягләму мәә бәйнә әйдииhим вә мәә хальфәhум, вә ләә йухиитуунә бишәйим-мин гильмиhии илләә бимәә шәәәә. Вәсига курсиййухус сәмәәвәәти вәль ард. Вә ләә йәъудуhүү хифзуhумәә вә hуәль галийуль газыйм”.**

**Иман**

**Тема:** Пәйгамбәрләргә иман китерү.

Кешеләрне бәхетле итәр, үзара күркәм булуны өйрәтер өчен Аллаhы Тәгалә бик күп пәйгамбәрләр җибәргән. Аларның hәркайсы кешеләрдән булган. Алар яшь вакытларында да бик акыллы, зирәк, гадел hәм изге табигатьле булганар. Олы булганнан соң Аллаhы Тәгалә аларны пәйгамбәр итеп сайлаган hәм алар кешеләрне хак дингә hәм изге гамәлләргә өндәгәннәр.

**<u>Дәрес 21</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Исраф.

Исраф – акча, мал hәм Аллаh тарафыннан безгә бирелгән нигъмәтләрне сәбәпсез туздыру яки әрәм итүдер. Аллаh Тәгалә исраф  кылучыларны сөйми. Исрафның киресе саранлыктыр. Исраф та, саранлык та ислам динендә тыелган. Коръәндә Аллаh Тәгалә болай дигән:  “Әй, адәм балалары, мәчеткә барганда яхшы киемнәр киеп барыгыз. Ашагыз, эчегез, ләкин исраф итмәгез, чөнки Аллаh исраф кылучыларны сөймәс”.

“Җәйгә планнар” ( “Балаларга иң кирәкле догалар” китабыннан).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Аятел Көрси.

**“Әллааху ләәәә иләәһә иллә һуваль Хәййүль Каййуум. Ләә тәъхузуһүү синәту-вә-ләә нәуум. Ләһү мәә фис сәмәәвәәти вә мәә филь ард. Мән зәльләзии йәшфәгу, гиндәһү иллә би-изниһ. Ягләму мәә бәйнә әйдииһим вә мәә хальфәһум, вә ләә йухиитуунә бишәйим-мин гильмиһии илләә бимәә шәәәә. Вәсига курсиййухус сәмәәвәәти вәль ард. Вә ләә йәъудуһүү хифзуһумәә вә һуәль галийуль газыйм”.**

**Иман**

**Тема:** Пәйгамбәребез Мөхәммәд гәләйһиссәләм.

Иң әүвәлге пәйгамбәр Адәм гәләйһис-сәлам, иң соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд сгв. Пәйгамбәребез Мөхәммәд сгв Ахыр заман пәйгамбәре, аннан соң дөньяга һичбер пәйгамбәр килмәячәк. Ул үзенең күркәм холкы белән барыбызга да үрнәк.

**<u>Дәрес 22</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Батырлык һәм куркаклык.

Батырлык – ул кыю, көчле, тәвәккәл, акыллы, тырыш, зиһенле, игътибарлы, җитез дигәнне аңлата. Ләкин батыр булу өчен бу гына җитми әле. Пәйгамбәребез сгв-нең мондый хәдисе бар: “Сугышта көрәшеп җиңгән кеше түгел, ә ачу килгәндә дә үз-үзен тыеп кала алган кеше көчле була”, - дигән.

Батыр булу өчен куркак булмаска кирәк, ә аның өчен дөреслек ягында булырга һәм үз-үзеңдә ышаныч булдыру мөһим.

“Рекорд” ( “Балаларга иң кирәкле догалар” китабыннан).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Азан догасы

**“Аллаһуммә Раббә һәәзиһид-дәгъвәтит-тәәәммәәти вәс-саләәтил-кааа-имәһ. Әәти Мүхәммәдәнил-вәсииләтә вәл-фәдыйиләтә вәд-дәраҗәтәл-гаалийәтәр-рафигаһ. Вә-бгасһү мәкаамәм-мәхмүүдәнил-ләзии вәгаттәһ. Вәрзүкнәә шәфәгатәһүү йәүмәл-кыйәәмәһ. Иннәкә ләә түхлифүл-мигәәд”.**

**Иман**

**Тема:** Китапларга иман китерү.

Аллаһ Тәгалә дин хөкемнәрен аңлатып, пәйгамбәрләренә Китаплар иңдергән. Аларга Аллаһның кешеләргә әмер иткән һәм тыйган нәрсәләре язылган. Пәйгамбәрләр шул китаплардагы хөкемнәр белән халыкларын иманга һәм изге гамәлләр кылырга өндәгәннәр.

Тәүрат китабы – Муса пәйгамбәргә, Зәбур китабы – Даут пәйгамбәргә, Инҗил китабы – Гайсә пәйгамбәргә, Коръән китабы – Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелә.

**<u>Дәрес 23</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Туган җирне, туган телне ярату.

Һәр кешенең беренче көннән үк туплый башлаган хәзинәсе – туган тел. Һәр милләт кешесе өчен иң матур, иң кадерле тел – үзенең туган теле. Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Ул Ватан, туган җир, ата - ана сүзләре белән бергә торган изге һәм кадерле сүз! Туган җир, туган йорт, туган авыл, Ватан! Болар — җанга иң якын сүзләр. Туган ил бишектән, әти-әни йорты бусагасыннан, урамда үсеп утыручы каеннан, язын ак чәчәккә төренә торган хуш исле шомырттан башлана. Без барыбыз да туган җиребезне һәм туган телебезне яратабыз.

Тукай Г. “Туган тел”.

**Гыйбадәт**

**Тема: Азан догасы.**

**“Аллаһуммә Раббә һәәзиһид-дәгъвәтит-тәәәммәәти вәс-саләәтил-кааа-имәһ. Әәти Мүхәммәдәнил-вәсииләтә вәл-фәдыйиләтә вәд-дәраҗәтәл-гаалийәтәр-рафигаһ. Вә-бгасһү мәкаамәм-мәхмүдәнил-ләзии вәгаттәһ. Вәрзүкнәә шәфәгатәһүү йәүмәл-кыйәәмәһ. Иннәкә ләә түхлифүл-мигаад”.**

**Иман**

**Тема:** Коръән Кәрим.

Коръән Кәримне Аллаһ Тәгалә Рәсүлебез Мөхәммәд сгв-гә 23 ел дәвамында Җәбраил фәрештә аркылы иңдергән. Коръән Кәрим Пәйгамбәребез сгв-нең могҗизасы булып тора. Ул гарәп телендә иңдерелгән һәм Аллаһ тарафыннан иңдерелгән ахыргы Китап булып санала. Коръән Кәримдә барлык кешеләргә, ике дөньяда да бәхетле булырга сәбәп булучы шәригать язылган. Анда һәр заманга һәм һәр урынга яраклы булган мәңге һәм ахыргы хөкемнәр килгән.

**<u>Дәрес 24</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Тыйнаклык һәм мактану.

Пәйгамбәребез гәләйһиссәләм әйтте: “Һәрбер диннең үзенең үзенчәлеге бар, Ислам диненең үзенчәлеге тыйнаклык”. Түбәнчелекле булу һәм тыйнаклык кешегә гыйлем алырга ярдәм итә. Мактану – ул урынсызга үз-үзеңне яки берәр эшеңне мактау, булмаганны арттырып сөйләү, шапырыну, масаю.

Алиш А. “Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык”, “Мактанчык” (“Балаларга иң кирәкле догалар” китабыннан).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Азан догасы.

**“Аллаһуммә Раббә һәәзиһид-дәгъвәтит-тәәәммәәти вәс-саләәтил-кааа-имәһ. Әәти Мүхәммәдәнил-вәсииләтә вәл-фәдыййиләтә вәд-дәраҗәтәл-гаалийәтәр-рафигаһ. Вә-бгасһү мәкаамәм-мәхмүдәнил-ләзии вәгаттәһ. Вәрзүкнәә шәфәгатәһүү йәүмәл-кыйәәмәһ. Иннәкә ләә түхлифүл-мигаад”.**

**Иман**

**Тема:** Тәкъдиргә иман китерү

Без, Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан дип иман китерәбез. Язмышның сиңа ошаганы да, ошамаганы да Аллаһы Тәгаләдән һәм алар барысы да хәерлегә була, дип ышанабыз. Тәкъдир – һәр нәрсә микъдар, үлчәнгән дигәнне аңлата. Дөньяда булачак нәрсә һәм башкарылачак эшләрнең һәркайсы Аллаһка мәгълүм.

## Дәрес 25

### Әхлак

**Тема:** Дуслык. Татулык.

Мөселман бала тәрбияле булып, Аллаһы Тәгалә сөйгәннәрне эшли һәм ул дусларын һәм күршеләрен дә хөрмәт итә. Дуслар алар әти-әни һәм туганнардан соң иң якын кешеләр. Шуның өчен мөселман баласы дуслары белән күркәм мөгамәләдә була, дусты килмәсә, аның турында сораша, дуслары авырсалар, хәлләрен белешә, ярдәм итә, шатлык һәм кайгыларын уртаклаша. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйтте: "Сездән берегез дә мөэмин булмас, үзе яраткан нәрсәне кардәше өчен дә яратмаса."

Алиш А. "Чукмар белән Тукмар".

### Гыйбадәт

**Тема:** Азан догасы.

**"Аллаһуммә Раббә һәәзиһид-дәгъвәтит-тәәәммәәти вәс-саләәтил-кааа-имәһ. Әәти Мүхәммәдәнил-вәсииләтә вәл-фәдыйиләтә вәд-дәраҗәтәл-гаалийәтәр-рафигаһ. Вә-бгасһү мәкаамәм-мәхмүдәнил-ләзии вәгаттәһ. Вәрзүкнәә шәфәгатәһүү йәүмәл-кыйәәмәһ. Иннәкә ләә түхлифүл-мигаад".**

### Иман

**Тема:** Ахырзаман һәм Кыямәт көненә иман китерү.

Бу көнне кешеләр дөньялыкта кылган яхшы һәм яман гамәлләре өчен Аллаһ алдында хисап тоталар һәм тиешле бүләк яки җәза алалар.

## Дәрес 26

### Әхлак

**Тема:** Кем ул әдәпле һәм тәрбияле бала?

1. Ул үзенең көнен Аллаһыга мактаулар әйтеп башлый һәм тәмам кыла.

2. Кылган гөнаһлары өчен тәүбә кылып, Аллаһыдан үзен гафу итүен сорый һәм үзенең хатасын таный белә.

3. Аның йөрәгендә беркемгә карата ачу да, көнчелек һәм үч алу хисләре булмый.

4. Ятим-мескеннәргә карата рәхим-шәфкатьле, мәрхәмәтле була. Олыларны, әти-әнине, укытучы һәм тәрбиячеләрен хөрмәт итә, кечкенәләргә карата миһербанлы була.

5. Аллаһка шөкер итә, тәкәбберләнми, мактанмый, кеше әйберенә рөхсәтсез кагылмый.

Тәрбияле бала һәр яктан үрнәк була.

Гомәрова З. "Үзем җыештырдым", Аппакова Д. "Рөстәм" ( "Тәмле сүз" китабыннан).

**Гыйбадәт**

**Тема:** Ике рәкәгать намазны кабатлау.

**Иман**

**Тема:** Җәннәт.

Җәннәт – ул мөселман кешесенең мәңгелек яшәү урыны. Анда бик рәхәт. Анда авырулар да, ямьсезлекләр дә, начарлыклар да юк. Ул зиннәтле сарайлар һәм җимешле бакчалар белән тулыдыр. Һәр җирендә татлы сулы елгалар һәм ширбәтле чишмәләр агып тора. Анда кергән изге кешеләр дөньяда һич кемнең күзе күрмәгән һәм колагы ишетмәгән ләззәтле нигъмәтләр белән хөрмәт ителәчәк. Ә иң мөһиме – җәннәттә мөселман кешесе Аллаһ Тәгаләне күрә алачак. Безгә әти-әниләребез, туганнарыбыз, иптәшләребез белән бергә җәннәткә керергә насыйп булсын.

**<u>Дәрес 27</u>**

**Әхлак**

**Тема:** Исламда бәйрәмнәр.

Бәйрәмнәр кешеләрнең тормышында мөһим бер вакыйга булып торалар. Бәйрәмнәр кешеләр арасындагы бергәлекне арттыра, кардәшлекне арттыра, гает көннәрендә кешеләр, мәчетләрдә күрешеп, бер-берләре белән йөрешеп, араларындагы дуслыкны сафландыралар. Ислам динендә Ураза гаете, Корбан гаете бәйрәмнәрдән санала, ә җомга көне гаеттән дә олы көн.

**Гыйбадәт**

**Тема:** Ике рәкәгать намазны кабатлау.

**Иман**

Тема: Кабатлау

Ислам диненең 5 баганасын, Иман нигезләренең 6 баганасын кабатлау.

## 7. ДОГА ҮРНӘГЕ

ӘЛХӘМДУЛИЛЛӘХ, ӘЛХӘМДУЛИЛЛӘХ, ӘЛХӘМДУЛИЛЛӘХИ РАББИЛ ГАЛӘМИН. БАРЛЫК МАКТАУ-ШӨКЕРЛӘРЕБЕЗ АЛЛАҺ ТӘГАЛӘГӘ. БУ ДӨНЬЯГА ХАЛЫК КЫЛУЧЫ ДА, ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ ДӘ, РИЗЫКЛАНДЫРУЧЫ ДА АЛЛАҺ.

ӘЙ РӘХИМЛЕ, МӘРХӘМӘТЛЕ, РӘХМӘТЛЕ РАББЫМ БЕР АЛЛАҺ. БЕЗНЕ ҮЗЕҢНЕҢ РӘХМӘТЕҢ БЕЛӘН ГЫЙЛЕМ ЙОРТЫҢА КИТЕРДЕҢ, ИНДЕ БЕЗГӘ ХӘЕРЛЕ, ФАЙДАЛЫ, ДӘВАМЛЫ, ГЫЙЛЕМ БИР. АЛГАН ГЫЙЛЕМНӘРЕБЕЗ БЕЛӘН ГАМӘЛ КЫЛЫП, КУШКАНАРЫҢНЫ ҮТӘП, ТЫЙГАННАРЫҢНАН ТЫЕЛЫП, АКЫЛЛЫ, ТӘҮФИКЪЛЫ, САУ-СӘЛАМӘТ БУЛЫП ҮСӘРГӘ НАСЫЙП ИТ. БЕЗГӘ, ӘТИ-ӘНИЛӘРЕБЕЗГӘ, КАРДӘШ-ТУГАННАРЫББЫЗГА, БАРЛЫК МӨСЕЛМАННАРГА ИМАН БАЙЛЫГЫ, БЕРДӘМЛЕК, НАМАЗ ӘҺЕЛЛӘРЕННӘН КЫЛ. Я РАББЫМ АЛЛАҺ, ДИНЕБЕЗГӘ, МИЛЛӘТЕБЕЗГӘ ФАЙДАЛЫ, КОРЪӘННЕ ӨЙРӘНЕП, АНЫҢ БЕЛӘН ГАМӘЛ КЫЛЫП, БАШКАЛАРГА ДА ӨЙРӘТҮЧЕЛӘР БУЛЫП ҮСӘРГӘ, АЛЛАҺКА ҺӘМ ӘТИ-ӘНИЛӘРЕБЕЗГӘ ИТӘГАТЬЛЕ БУЛЫРГА НАСЫЙП ИТ.

ӘЙ, ЯРЛЫКАУЧЫ РАББЫМ АЛЛАҺ. ВАФАТ БУЛГАН ӘТИ-ӘНИЛӘРЕБЕЗНЕҢ, ӘБИ-БАБАЛАРЫБЫЗНЫҢ ГӨНАҺЛАРЫН ГАФУ КЫЛ.

Я РАББЫМ АЛЛАҺ, БЕЗНЕҢ САФЛАРЫБЫЗНЫ АРТТЫР, ИКЕ ДӨНЬЯ БӘХЕТЕН БИР, ВӘГЪДӘ ИТКӘН ФИРДӘВЕС ҖӘННӘТЕҢДӘ ОЧРАШТЫР. СИНЕҢ АЧУЫҢ ТӨШӘ ТОРГАН ГАМӘЛЛӘРДӘН САКЛА.

ӘМИН, ӘМИН, ӘМИН РАББИЛ ГӘЛӘМИН.

# 8. КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Коръән Кәрим

2. Ислам дине нигезләре – Казан: “Хозур”- “Тынычлык” нәшрияте йорты, 2017. – 608 б.

3. Балаларга үгет-насыйхәт. Казан: “Дом печати” нәшрияты.- 2002. – 176б.

4. Ислам дине нигезләре – Казан: “Хозур”- “Тынычлык” нәшрияте йорты, 2017. – 608 б.

5. Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балаларын ислам диненең рухи-әхлакый кыйммәтләре белән таныштыру программасы (төзүчеләр: К.В. Закирова, В.С.Казыйханов). – Казан: РИЦ “Школа”, 2006. – 32 б.

6. Максуди Әхмәдһади. Гыйбадәте исламия. – Казан: Идел-Пресс, 2013. – 112 бит.

7. “Әхлак дәресләре” . Укытучылар, сыйныф җитәкчеләре һәм тәрбиячеләр өчен дәрес эшкәртмәләре. Казыйханов В.С. “Яр Чаллы” нәшр. – 1998.

8. “Мәгърифәтче – галим, педагог Ризаэддин Фәхреддингә багышланган педагогик укулар программасы”. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, 2006

9. Көч һәм рух тамырлары: Әдәплелек дәресләре: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1998. – 223 б.

10. Мин динемне яратам / (төз.-авт. Г.Гайнетдинова). – Казан: “Идел-Пресс” типографиясы, 80б.

11. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан: РИЦ, 2011. – 560 б.

12. Иң матур сүз: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия / (төз.-авт. К.В. Закирова). – Яңарт.3 нче басма. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015.- 431б.

13. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. Дәреслек. – Яр Чаллы: “Ислам нуры” эшмәкәрлек үзәге. - 2012. – 257б.

14. Тәмле сүз: әдәпле булу серләре / (төз. Талия Шакирова; рәссамы Алсу Тимергалина). – 2нче басма. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. – 79 б.: рәс. б-н.

15. Макарова Динә. Балаларга иң кирәкле догалар – дини тәрбияви хикәяләр, Казан: “Идел-Пресс” полиграфия-нәшрият комплексы, 2013. – 80 б.

16. Макарова Дина. Маленький мусульманин, Нижнекамск: “Рисаля”, - 2013.- 80стр.


17. Профессор М.Яшар Кандемир. 40 хадисов в рассказах. Перевод с турецкого. М.: ООО “Издательская группа “Сад”, 2009. 4-е издание. – 96 стр.

18. Прекрасные имена Аллаха. Поучительные истории. – СПб.: Издательство “Диля”, 2015. – 128стр.

19. Әхмәд Һади Максуди “Мөгаллим сәни”. Казан: “Хузур”, 2015.


20. Ногмани тәфсире. Казан: ПИК “Идел-Пресс”, 2010.

Кушымта




______________________


Бала исеме





Бала исеме




Бала исеме




Бала исеме




Бала исеме